# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

1/ 2022

*«...Татарның матур сыйфаты – кунакчыллык.
Иң әүвәлге төп сые – чәй. Син аны дүрт касәдән дә ким
эчеп туктый алмыйсың (ярлыракларда бал белән).
Өстәлгә бик куе итеп туглаган каймак куела.
Кура җиләге кагы, кайнар табадан гына төшкән коймак».*

***Карл Фукс.***
***«Казан һәм татарлар турында»***








TATARSTAN



# 2022 ел – Россия халыкларының мәдәни мирасы елы

*«...Мәдәният халык хәтерен гасырлардан гасырларга озын көйләр, туган тел авазлары, балчык сыбызгы яки бизәкле яулыклар аша бүгенгә китереп җиткерә алган. Мәдәни мирас – безнең фондлар һәм ядкәрләр генә түгел, ул халкыбызның кадерләп буыннан буынга тапшырылган рухи традицияләре дә. Мәдәни мирасны саклау, өйрәнү һәм баету – мәдәният тармагының төп максаты. Ул Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең өстенлекле бурычларының берсе булып, 2021 елда кабул ителгән, 2030 елга кадәр дип билгеләнгән Татарстан Республикасы мәдәниятенең үсеш стратегиясендә дә үз чагылышын тапты».*

***Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпованың йомгаклау коллегиясендәге чыгышыннан***
*21 гыйнвар, 2022 ел*



Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Түгәрәк уен

№ 1 / 2022

*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*

16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590.
Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 15.03.2022
Чыгу көне: 26.03.2021
Заказ: 065113
Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:
420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта:** «Тантана» *сервизы. Рәссам Наилә Кумысникова*

© «Түгәрәк уен», 2022

**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**

4 **Тукучылык: сәнгать, традицияләр**

8 **XXI төбәкара «Идел-йорт-2021» театр коллективлары конкурсына йомгак ясалды**

10 **«Уникаль Россия» II сәнгать-сәнәгать күргәзмә-форумы**

**ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ**

12 Ф. Мәрданова
**Изү – татарның күкрәк бизәгече...**

**МАТУРЛЫК**

18 Н. Кумысникова
**«Тантана» сервизы**

**ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...**

24 Е. Шемелова
**Хан кызы серләре**

30 Э. Мозаффарова
**Балык Бистәсен Америкага таныткан челтәр**

**ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ**

35 Л. Вафина
**Калатауда айлы манара, тарихыбыз шуннан башлана...**

**БЕЗГӘ ЯЗАЛАР**

39 Г. Хөсәенова
**Кендек әбиләре**

40 Р. Галкина
**«Качману» ашы**














ӘДӘБИ МИРАС

42 Л. Мөхәммәтҗанова
**Халык иҗатында дини-мифик йолалар**

СӘХНӘ

46 Л. Сәгыйрова
**«Балкыш» халык театрының тарихи мизгелләре**

МИЛЛИ УЕННАР

51 Ә. Мөхәммәтҗанов
**Милли мәдәнияткә – милли уеннар аша**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...

56 **«Uen Fest-Уен Фест»: иҗади смена**

58 Ә. Ситдыйкова
**Карга боткасы**

58 **Укучылар иҗаты**

59 **Җир йокысы** *(Җыр)*

ӨЙ КҮРКЕ – АШ

60 **Милли аш-суның барлыкка килү тарихыннан**

61 **Кош теле**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

64 **Шахворд**

# Тукучылык: сәнгать, традицияләр



Тукучылык буенча халыкара симпозиум – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының уртак проекты. Симпозиум алдыннан 2021 елның 27 июнь – 3 июль аралыгында кырымтатар остасы Мамут Чурлу Кырым Республикасының Симферополь районы Перевальное авылында укыту семинары уздырды. Актаныш, Бөгелмә, Буа, Чаллы, Кукмара, Казан музейлары хезмәткәрләре, Балалар сәнгать мәктәпләре, төрле уку йортлары укытучылары табигый буяулар белән эш итү һәм ике төрле туку буенча күнекмәләр алды.

2021 елның 16-17 декабрь көннәрендә Казанда үткән «Күп милләтле тукучылык






Невинности моей и юности обитель!
Калейдоскоп культур
Слово о ткачестве
Чувашский орнамент





сәнгате» халыкара симпозиумы татар сәнгатенә нигез салучы Фуад Вәлиевнең 100 еллыгына багышланган иде.

Симпозиум А.С. Пушкин исемендәге мәдәният үзәгендә ачылды. «Глобаль процесслар дөньяны бертөрлегә әверелдергәндә, төсле буяуларга манып, безнең үзтәңгәллегебезне күрсәтә алучыларга рәхмәт. Күп гасырлардан килгән традицияләр җебен өзмәвегез өчен рәхмәт!» – диде симпозиумны ачканда Татарстанның Мәдәният министры Ирада Әюпова.

Симпозиумда Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Азәрбәйҗан илләреннән һәм Россия регионнарыннан галимнәр чыгыш ясады.

Шунда ук бүгенге осталар эшен тәкъдим иткән «Заманча тукучылык» дип аталган күргәзмә дә эшләп торды. Традицион стильдәге тукылган костюмнар дефилесендә Алексеевск сәнгатьле туку фабрикасы, Алнаш һөнәр һәм туризм үзәге (Удмуртия), Үзәй-Тукля һөнәр һәм туризм үзәге Увин районы артеле (Удмуртия), «Браные узоры» (Чувашия) вәкилләре катнашты.













Удмуртская Республика
Автономная некоммерческая организация
Алнашский
дом ремёсел

# XXI төбәкара «Идел-йорт-2021» театр коллективлары конкурсына йомгак ясалды

1998 елдан башлап, Шамил Закиров исемендәге «Идел-йорт» төбәкара конкурсы ел саен Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе төбәкләреннән театр коллективларын җыя. Конкурсның максаты – һәвәскәр театр иҗатын үстерү һәм җәелдерү, башкару осталыгын камилләштерү, үзешчән артистларның һәм куючы режиссерларның иҗади мөмкинлекләрен киңәйтү.

Бәйгене Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге, Бөтендөнья татар конгрессы, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры гамәлгә куя.

Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы 2021 елның декабрендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры сәхнәсендә үтте. Җиңүчеләргә Гран-при, лауреат исемнәре һәм һәр номинация буенча акчалата сертификатлар тапшырылды. Театрның затлы сәхнәсеннән Питрәч районы «Балкыш» халык театрының Гран-прига ия булган спектакле – Мансур Гыйләҗев пьесасы буенча куелган «Казан егетләре» (режиссеры Фәнил Мисалов) комедиясе күрсәтелде.










Идел-Йорт

Әлеге конкурста Флорид Бүләков пьесасы буенча сәхнәләштерелгән «Сөясеңме-сөймисеңме?» спектакле өчен Башкортстан Республикасы Кушнаренко районының «Мизгелләр» халык театры да Гран-прига ия булды (режиссеры Энҗе Гыймалетдинова).

1 нче дәрәҗә лауреат исеменә Авксентий Цагарели пьесасы буенча сәхнәләштерелгән «Ханума» спектакле өчен Азнакай шәһәренең «Район һәм шәһәр мәдәният йорты» халык театры коллективы (режиссеры Гөлсинә Жамалиева) һәм Мансур Гыйләҗев пьесасы буенча «Яра» спектакле өчен Башкортстан Республикасы Октябрьск шәһәренең «Чулпан» үзешчән театр коллективы (режиссеры Раушания Фәезова) лаек булды.




# «Уникаль Россия» II сәнгать-сәнәгать күргәзмә-форумы

Татарстанның халык һөнәрчелеге осталары Мәскәүдә узган «Уникаль Россия» II сәнгать-сәнәгать күргәзмә-форумында катнашты. Әлеге күргәзмә-форум Россия халыкларының мәдәни мирасы елының үзенчәлекле ачылу тантанасына тиң иде.

Күргәзмәдә республиканың күренекле осталары Л.Ф. Фәсхетдинова, Р.А. Мөхәм-мәтшин, Р.Х. Әхмәтов, Н.Е. Гыймадиева, Л.Н. Низамова, Ф.А. Ханбеков, Д.Г. Вилда-новлар, «Buro Banu», «Презент», «Сәхтиян», «Миллихаситә» оешмалары, Алексеевск





нәфис туку фабрикасы үз товарларын тәкъдим итте. Күргәзмәдә Н.И. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы, Казан дәүләт мәдәният институты, Казан халык һөнәрчелеге техникумы декоратив-гамәли сәнгатьне мәгариф системасы аша күрсәтә алдылар.

Сәнгать-сәнәгать күргәзмә-форумы кысаларында этно-дизайнерлар – «Buro Banu» ательесы, «Миллихаситә» иҗат берләшмәсе һәм Солтан Салиев үзенең коллекциясен тәкъдим итте. «Тамгадан авангардка кадәр» дип аталган каталогның да презентациясе биредә үтте.

«Тамгадан авангардка кадәр» – республикада халык һөнәрчелеге үсеше тарихын чагылдырган беренче басма. Каталог Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән дөнья күрде.










Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

*Филүзә МӘРДАНОВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең матди булмаган мәдәни мирас бүлеге мөдире*

# ИЗҮ – татарның күкрәк бизәгече…




**Изү. «Buro Banu» ательесы архивыннан**

***Элек-электән татар хатын-кызлары традицион бизәнү әйберләрен бик теләп, яратып кулланганнар. Алар киемнең иң якты элементлары булып, милли костюмны тулыландырып торганнар. Күптөрле традицион бизәнү әйберләре арасында тукыма күкрәкчәләр аерым игътибарга лаек. Әлеге төр күкрәк бизәгеч 20х30 сантиметрдан алып, 25х40 сантиметрга кадәрле, өске ягы трапеция формасындагы турыпочмаклы йомшак тукыма кисәгеннән гыйбарәт. Аны күлмәктәге күкрәк уемын каплар өчен кулланганнар: махсус бәйләвечләр ярдәмендә муенга бәйләп куйганнар.***

Бизәү алымына бәйле татар хатын-кызларының өске күкрәкчәләрен дүрт төркемгә берләштереп карарга мөмкин. Беренче төркем – тәңкәләр белән бизәлгән «түшлек»ләр. Күкрәкчәнең алгы ягы кара, яки сирәгрәк – кызыл тукыма белән капланган. Формасы буенча әлеге күкрәкчәләр ике вариантта очрый: 1) аскы почмаклары түгәрәкләнеп килгән турыпочмаклы; 2) почмаклары түгәрәкләнмәгән турыпочмаклы[1].

Мондый күкрәкчәләр Идел буе һәм Урал алды халыкларының күбесендә очрый. Әмма һәрберсенең үзенә генә хас бизәкләү рәвеше һәм орнаментлары бар. Тәңкәләр белән бизәлгән күкрәкчәләрне сергач мишәрләрендә (көмеш күкрәк), башкортларда (һакал), чуашларда (ама), көнчыгыш мариларда (налме мел), казахларда (алма), кыргызларда (ала тамак) очратырга мөмкин[2]. С.В. Суслова фикеренчә, түшлекләр шушы җирлектә яшәгән фин-угор халкы традицияләре йогынтысында формалашкан[3]. Казан татарларының мондый бизәнү әйберләре XVIII гасырда ук И.Г. Георгида[4], соңрак, М. Лаптевта[5], А.Ф. Риттихта[6] телгә алына.

Икенче төркем – «алынча», алтын җепләр белән бизәлгән озынча ярымтүгәрәк күкрәкчәләр. Бу төр күкрәк каплагычлар Пенза, Сембер һәм Саратов губернияләре татар-мишәрләрендә еш очрый. Алты яки




**Изү. XX гасыр башы. Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан**

сигез чуклы чәчәк – чигүнең үзәк орнамент мотивы булып тора. Чәчәк нурлары кайчакта икегә аерылып, яфраклы үсенте рәвешен ала яки үзәк нокта тирәсендә бөтерелә. Түгәрәк үзәге аша үткән нурлар кояшка охшаш рәсем хасил итә. Мөгаен, бу саклау

[1] Суслова С.В. Женские украшения казанских татар середины XIX – начала XX в. – М.: Наука, 1980. – С. 44.
[2] Там же. – С. 45.
[3] Суслова С.В. Татарский костюм: историко-этнологическое исследование. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. – С. 141.
[4] Георги И.Г. Описание всех обитающих в Российском государстве народов, их житейских обрядов, обыкновений, одежд, жилищ, упражнений, забав, вероисповеданий и других достопамятностей. О народах татарского племени. – СПб.: Изд-во Императорской Академии наук, 1799. – Ч. 2. – С. 13.
[5] Лаптев М. Материалы для этнографии и статистики России: Казанская губерния. – СПб., 1861. – С. 217.
[6] Риттих А.Ф. Материалы для этнографии России: Казанская губерния. – Казань, 1870. – С. 20-21.



**Изү. XX гасыр башы.**
**Парча, атлас һәм укалы тасма.**
**Җиз тәңкәләр һәм сердолик бизәнгечләр тегелгән.**
**Яңа Чишмә районының Туган якны өйрәнү музеенда саклана**



**Суслова С.В. «Женские украшения казанских татар середины XIX – начала XX в.» китабыннан, 116 нчы бит.**
**1 – «изү»; 2 – «түшлек»; 3 – «сакал»; 4 – «түшлек»; 5–7 – хәситә**

функциясен үтәүче кояшны (солярный знак) аңлаткан борынгы билгедер[7]. Кайбер очракларда композиция уртасындагы әлеге билге күп яфраклы һәм чәчәкле ботак мотивы белән алыштырыла. Ботак үзе дә, яфраклары да үзәккә таба бөтерелеп килә. Бу вариация татарның алтын җеп белән чигешендә киң таралган[8].


Күкрәкчәләрнең «яга» /«яка» дип аталган өченче төркеме Урал арты татарларына һәм башкортларга хас. Бу күкрәкчәләр чын яки ясалма коралл мәрҗәннәр, еш кына коралл мәрҗәнле чуклар, тәңкәләр белән бизәлә. Әмма күкрәкчәләрнең беренче төркеме – түшлекләрдән аермалы буларак, җиз тәңкәләр монда төп декоратив элемент булып тормый[9].

Күкрәкчәләрнең «изү» дип аталган дүртенче төркеме татарлардан һәм башкортлардан кала башка халыкларда очрамый. С.В. Суслова фикеренчә, изүне «Идел буе һәм Урал алды татарлары мәдәниятенең этноүзенчәлекле элементы» итеп карарга мөмкин[10].

Изү аскы почмаклары түгәрәкләнгән дүртпочмаклы йомшак тукыма кисәгеннән (күп очракта бәрхет) гыйбарәт. Ул эре көмеш тәңкәләр, төймәләр, сәйләннәр, укалы тасмалар белән бизәлә. Изүнең кырыйлары төсле тукыма белән каймалап алына.

Кайбер галимнәр фикеренчә, бу төр күкрәкчәләр ак киндердән тегелгән күлмәкләрнең күкрәк уемын, җиңнәрен, итәген чигеп бизәү традициясеннән барлыкка

[7] Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала середина XIX – нач. XX вв. – Казань: Фән, 2000. – С. 107.
[8] Фасхутдинова Л.Ф. Золотное шитье татар-мишарей: особенности техники и орнамента // Этнографическое обозрение. – 2015. – № 4. – С. 172.
[9] Суслова С. В. Татарский костюм: историко-этнологическое исследование... – С. 141.
[10] Там же. – С. 139.



**Хатын-кыз костюмы. Изү һәм алтын җепләр белән чигелгән калфак. Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана. Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.Г. «Декоративно-прикладное искусство казанских татар» китабыннан, 67 нче бит**



**«Эбиволь» компаниясе осталары әзерләгән изү. «Эбиволь» компаниясе архивыннан**

килгән[11]. XIX гасырда әлеге тукыма кулланылмый башлый. Аны төсле алача, соңрак ситсы алыштырган. Мондый төр чуар тукымадан тегелгән күлмәкләрнең күкрәк уемы тирәсендә чигелгән орнаментлар күренмәү сәбәпле, күкрәк өлешен тукыма аппликация белән каплый башлаганнар. Вакытлар үтү белән әлеге аппликация кием ансамбленең мөстәкыйль бер элементы – изү буларак формалаша[12]. Бу очракта без күлмәк уемына куелып, күкрәкне саклау функциясен үтәгән тукыма кисәгенең махсус күкрәк бизәгечкә әверелүен күрәбез[13]. Казан татарларында күлмәк уемы тирәсенә тегелгән тукыма аппликация дә, күкрәккә киелә торган бизәк тә «изү» дип атала[14].

Н.И. Воробьев «изү»нең барлыкка килүен җирле фин-угор халыкларында күлмәк түшен чигеп бизәү традициясе белән бәйләп аңлата[15]. Әмма алдарак билгеләп үтелгәнчә, күлмәк уемын фин халыклары гына түгел, татарлар да[16], башкортлар да[17] бизәгән. «Бай татар хатыны аның (күлмәкнең) күкрәген – төймәли торган урынын чигә»[18], – дип яза И.Г. Георги.

С.В. Суслова фикеренчә, Казан татарларының «изү»е төрле яшьтәге хатын-кызлар өчен мәҗбүри бизәнү әйбере булып саналган[19]. Н.И. Воробьев исә изүнең бары кияүдәге ханымнарның күкрәк бизәгече булуын, туташларның күкрәкчәне бөтенләй киməүләрен ассызыклый[20]. Р.Г. Мөхәмәдова билгеләп үткәнчә, күкрәкчәнең дини-магик функциясе – бала имезгән хатын-кызның күкрәген ят күзләрдән каплап тору. Галимә фикеренчә, аның төп орнаменталь мотивлары һәм декоратив-сәнгати бизәү алымнары: соляр билгеләр, төсле тукыма кисәкләреннән аппликацияләр, борынгы мәҗүси символлар булып тора[21]. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, без изүне кияүдәге хатын-кыз кием комплексының бер элементы дигән нәтиҗә ясый алабыз.

Изү беркайчан да алъяпкыч яки камзол, кесәбикә кебек тышкы кием өстеннән киелмәгән. Ә татарларның башка этник төркемнәре (аерым алганда, керәшеннәр) һәм башка халыкларның тәңкәле күкрәкчәләре алъяпкыч, хәтта җилән кебек кием өстеннән дә киелгәнлеге билгеле[22]. Якынча XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында күкрәк өлеше төймәләнә торган күлмәкләр барлыкка килгәч, изү кулланылыштан чыга[23]. Р.Г. Мөхәмәдова мәгълүматларына

[11] Суслова С.В. Женские украшения казанских татар... – С. 44.
[12] Завьялова М.К. Татарский костюм. – Казань: Заман, 1996. – С. 66.
[13] Гаген-Торн Н.И. Женская одежда народов Поволжья. Материалы к этногенезу. – Чебоксары: Чувашгосиздат, 1960. – С. 90.
[14] Там же. – С. 228.
[15] Воробьев Н.И. Казанские татары. Этнографическое исследование материальной культуры дооктябрьского периода. – Казань: Татгосиздат, 1953. – С. 301.
[16] Мухамедова Р.Г. Татары-мишари: историко-этнографическое исследование. – Казань: Магариф, 2008. – С. 91.
[17] Паллас П.С. Путешествие по разным провинциям Российского государства. – СПб.: Изд-во Императорской Академии наук, 1786. – Ч. 2. – Кн.1. – С. 98; Черемшанский В.М. Описание Оренбургской губернии в хозяйственном и промышленном отношении. – Уфа : изд. иждивением Учен. ком. М-ва гос. имуществ, 1859. – С. 155.
[18] Георги И.Г. Указ. соч. – С. 13.
[19] Суслова С.В. Женские украшения казанских татар... – С. 80.
[20] Воробьев Н.И. Указ. соч. – С. 244-245.
[21] Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Указ. соч. – С. 106-107.
[22] Суслова С.В. Женские украшения казанских татар... – С. 80.
[23] Суслова С.В. Татарский костюм: историко-этнологическое исследование... – С. 139.

караганда, андый күкрәкчәләр сирәк булса да XX гасыр урталарына кадәр өлкән буын ханымнарда очраштырган[24].

Күкрәкчә әзерләү өчен нигездә фабрикада тукылган йомшак тукыма кулланганнар. Үлчәме 20х30 сантиметрдан 25х40 сантиметрга кадәрле дүрт почмаклы, аскы почмаклары түгәрәкләнеп килгән кәгазьдән өлге киселгән. Ике катлап бөкләнелгән тукыма кисәгенә өлгене куеп акбур яки сабын кисәге белән контурны сызганнар. Кайчы ярдәмендә күкрәкчәнең өлешләрен кисеп, бер-берсенә тоташтырып тегеп чыкканнар, махсус бәйләвечләр беркеткәннәр.

Күкрәкчәне күкрәккә беркетүнең төрле ысуллары булган:

– күкрәкчәнең өске почмакларына электерелгән тасма белән муенга бәйләнгән;


– күкрәкчәнең аскы һәм өске почмакларына аркылы тегелгән тасмалар белән аркага электерелгән;

– күкрәкчәнең һәр почмагындагы дүрт тасма ярдәмендә беркетелгән[25].

Изүнең түгәрәкләнеп торган ягы буйлап берничә рәт укалы тасма, тукыма кисәкләре теккәннәр, аларга төймәләр, сәйләннәр беркеткәннәр. Тукымага тегеп кую өчен төрле зурлыктагы тәңкәләр кулланылган. Алар бер-берсен өлешчә каплап торырлык итеп тегелгән. Изүнең читләренә төсле җиңел тукыма тегеп чыкканнар.

Бүгенге татар ханымнары көндәлек тормышта изү кимиләр, аны бары милли бизәнү әйбере буларак кына кулланалар. Күкрәкчәләрне эксклюзив милли киемнәр җитештерү белән шөгыльләнгән ательелар, осталар тегәләр. Мәсәлән, инде 25 ел дәвамында заманча киемнәрдә милли традицияләрне яңартучы «Эбиволь» компаниясе осталары изүне тарихи аналоглары буенча да, заманча стильгә яраклаштырып та әзерли. Алар Татарстан Республикасы музейларында сакланып калган изү үрнәкләрен өйрәнә һәм милли традицияләрне торгызу өстендә зур эш алып баралар.

2017 елда Гөлнара Хамаева һәм Элара Шәйхи ачкан «Buro Banu» (Бюро Бану) авторлык ательесының эшчәнлеге дә зур



«Buro Banu» (Бюро Бану) ательесы осталары әзерләгән изү.
«Buro Banu» ательесы архивыннан

игътибарга лаек. Ателье осталары металл бизәкләр, декоратив тасмалар һәм чуклар белән натураль бәрхеттән изүләр тегәләр. «Россия ислам дөньясы: KazanSummit» Халыкара икътисади саммит кысаларында үткәрелгән «Kazan Islamic Clothes» Халыкара мода фестивалендә «Бану» коллекциясе «2018 елның иң яхшы бренды» дәрәҗәсенә лаек булды.

Кием дизайнеры Гөлфия Шәйдуллина-Билалова да изүләр тегү белән шөгыльләнә. Ул халыкара конкурслар лауреаты, «Россиянең иң яхшы мөселман дизайнеры» титулы иясе (2015), «Заманча костюмнарда иң яхшы этник мотивлар» (2017) номинациясендә «Иң яхшы коллекция» кубогы иясе. Яшь дизайнер Оренбург дәүләт университетының архитектура-төзелеш факультетын тәмамлаган. Ул үз эшләрендә борынгы бизәнү әйберләрен, татар костюмнарына хас төсләр гаммасын, бизәү рәвешен тергезә.

Бүгенге осталарның эшчәнлеге нәтиҗәсендә, онытылып баручы тарихи костюм элементы булган изү, үз киемнәрендә милли колоритка омтылган заманча ханымнарның бизәнү әйберенә әверелеп бара.

[24] Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Указ. соч.– С. 107-108.
[25] Там же. – С. 106.

*Наилә КУМЫСНИКОВА,*
*Татарстанның халык рәссамы*

# «ТАНТАНА» сервизы





*«…Ике гасыр дәвамында буйсындырылып, руслар арасына сибелгәч тә, гел үзайры яшәгән кебек, гореф-гадәтен, йолаларын, горурлыгын саклап кала алган гаҗәеп халык бу!*

*Иң матур сыйфаты – кунакчыллык. Татарның әүвәлге төп сые – чәй. Син аны дүрт касәдән дә ким эчеп туктый алмыйсың (ярлыракларда бал белән). Өстәлгә бик куе итеп туглаган каймак куела. Кура җиләге кагы, кайнар табадан гына төшкән коймак. Боларның һәммәсен кабып карарга тиешсең. Әмма моның белән генә бетми икән. Бөтенләй таныш булмаган тагын ике-өч татар сине кунакка алырга дип көтеп тора. Кире кага алмыйсың. Үпкәләячәкләр. Өйләренә кердеңме, кыстый-кыстый баллы камыр ризыклары белән сине тагын өчәр чынаяктан да ким чәй эчертмичә җибәрмиләр.*

*... Яхшы сыйфатлы фарфор, җете бизәкле кытай фарфорыннан эшләнгән чәшкә-чынаяк, савыт-сабаны бигрәк тә яратып кулланалар»*.*

***Карл Фукс.***
***Казан һәм татарлар турында***
***(Казан, 1844)***





*Марсель Галиев тәрҗемәсендә

Ике йөз елга якын вакыт узса да, татарларның традицияләрендә, гадәтләрендә бернәрсә дә үзгәрмәгән. Кунакчыллык та, кунак килешкә яки гаилә белән сыйланырга әзерләнгән камыр ризыклар һәм каймак белән чәй эчәргә ярату да шул ук. Бу традициянең мәгънәсе, әлбәттә, чәй эчү генә түгел, аның асылы тирәндәрәк. Табын янында ашыкмыйча гына әңгәмә кору, өлкән буынның хатирәләре, балаларның янып торган күзләре һәм игелекле бергәлек атмосферасы – менә нәрсә ул чәй эчү! Бу бер-ике чынаяк кына түгел, биш-алты чынаяктан да ким түгел, чәйнек бушый икән, чәй тагын пешерелә. Татар өендә чәй запасы бетми. Әти-әнинең һәм әби-бабайның тәмле чәй эчкәндә тормыш турында сөйләшүләре үзе бер гомер! Чәй эчүләр кабатланып торса да, аларның һәрберсе үзенчәлекле, әлеге табындагыларның берсе булу үзе зур бәхеттер кебек. Халыкның буыннардан буыннарга күчкән зирәклеге, ихласлыгы, җиңү шатлыгы һәм борчылулары чәй янындагы хатирәләр аша яшь буынга тапшырыла, пары чыгып торган тәмле чәй белән бергә яшьләр аны үз хатирәләренә күчерә һәм алдагы буыннарга тапшыру өчен күңел төпкеленә салып куя.

Бу шулкадәр зур әһәмияткә ия, вакытлар үткәч, әлеге хатирәләр шундый ук тәмле чәй табынында оныкларның хатирәсенә әвереләчәк.

Йортка көтелмәгән кунак килсә, ул бусаганы атлап та өлгерми, чәйнек инде кайный да башлый, кунак килә калса дип саклап тотылган тәм-том өстәлгә тезелә, андый сый булмаса, кемдер якындагы кибеткә йөгерә. Әбиләрнең яшерен почмакларында саклап тотылган конфетлар һәм гәрәбәдәй алма кайнатмасы да өстәлгә чыга, үзләре бәйрәмдә генә бәйләнәсе яулыкларын ябалар. Аралашу бәхетен, очрашу шатлыгын көткәндә чәй табыны әзерләү серле бер эш булып тоела, йөзләрдән елмаю китми, йортка нур иңә.



**«Тантана» сервизы ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан Эдуард Хәйруллин заказы белән Санкт-Петербургның Император фарфор заводында 2020 елда эшләнгән. Рәссам Н. Кумысникова. Сөяк фарфоры, «гөмбәз» формасы авторы Ю. Троицкий**

**«Көмеш Болгар» сервизы Мәрҗани фонды заказы белән Санкт-Петербургның Император фарфор заводында 2012 елда эшләнгән. Рәссам Н. Кумысникова.**
Сөяк фарфоры, «гөмбәз» формасы авторы Ю. Троицкий





**«Алтын Болгар» сервизы Мәрҗани фонды заказы белән Санкт-Петербургның Император фарфор заводында 2012 елда эшләнгән. Рәссам Н. Кумысникова.**
Сөяк фарфоры, «гөмбәз» формасы авторы Ю. Троицкий



**«Алтын гөмбәзләр» сервизы Мәскәү Җәмигъ мәчете ачылу уңаеннан Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте заказы белән Санкт-Петербургның Император фарфор заводында 2015 елда эшләнгән.**
**Рәссам Н. Кумысникова.**
Сөяк фарфоры, «гөмбәз» формасы авторы Ю. Троицкий

Табынга иң матур чынаяклар куела. Юка фарфор чынаяклардан җылы нур агыла кебек. Күпме чәй калганлыгы үтәли күренеп торган юка нәфис чынаякларның тантаналы ак ашъяулык өстенә тезелүе гүзәллекнең бер үрнәге булып тора. Алтынланып затлы җемелдәгән чынаякларның бизәкләренә сокланып карыйлар, әйләндереп кая ясалганлыгы белән дә кызыксыналар. Арадан кем дә булса, һичшиксез: «Мондый матур сервизны каян алдыгыз?» – дип сорап куя. Бу хәйлә инде, әлбәттә, чөнки аның тарихын бөтен кеше белә, әмма тыңлаган саен тыңлыйсы килә! Чөнки сервизны бүләк итүче яки сатып алучы искә төшерелә, фани дөньядан киткән булса да, ул үзен искә төшерүләренә куанып торадыр кебек... Барысы да фарфорны һәм аны алып кайтучыны мактыйлар – бу гадәткә кергән. Матур хатирәләр яңартыла. Өстәлдәге ризыклар матур савыт-сабага салына, зур табак белән ләвәшләр яки торт чыгарыла, йөзем, күрәгә, каражимеш, лимон, кайнатма куела. Кипкән җимешләр салынган чәй – иң татарча чәй, сөт салынганы да, әлбәттә. Кунакларның кучтәнәчләре дә өстәлдә урын ала, чөнки кунакка беркем дә буш кул белән килми – бу да борынгыдан калган матур гадәт. Иң соңыннан табынга кара чәй пешерелгән чәйнек килә – ул бик кадерләп табын уртасына утыртыла. Ниһаять, чәй эчелә башлый!

Чәй табыны якынайта дисәк, бу сүзләр генә табын артында хөкем сөргән атмосфераны бирә алмый. Табында бердәмлек тантана итә, әңгәмә мәрхәмәтлелек һәм аңлашу белән өртелгән, өстәл янынннан бер-береңә якынаеп, күңелләр бердәмлеге белән генә кузгаласың. Бәлки шуңадыр борынгыдан килгән кагыйдә бар – барлык мәсьәләләр чәй эчкәндә хәл ителә! Башта чәй, аннары проблемалар. Их! Акыллы һәм зирәк булган да инде безнең әти-әниләр, әби-бабайлар! Шушы түгелмени аңлашуга һәм бердәмлеккә омтылыш! Карл Фуксны сыйларга омтылыш та – яхшы дуслы булырга теләү омтылышы түгелмени?!





*«Мин бу чәй җәзасын берничә мәртәбә кичердем: ашказаным тирәнлегендә егерме биш чынаяк чәй мөлдерәтеп өемә кайтып авам да икенче көнне дару кабарга тотынам.*

*Күрше татар авылында мин берничә тапкыр гаиләм белән кунак булдым. Анда инде татарларның кунакчыллыгы бөтен балкышына ачылды; безнең хөрмәткә бөтен авыл бәйрәмчә киенгән, зур яулык бөркәнгән хатын-кызлар басу капкасы төбенә җыелган. Кунакка аласы ирләр әллә каян ук юлга каршы чыгып көтеп торалар иде.*

*Менә башлана инде хәзер чәй табыннары. Кимендә унбиш ызбада булырга кирәк. Безне көткән өйләрнең идәне ялт итеп юылган, киң эскәмияләргә юрган түшәлгән, вак мендәрләр салынган; стенада матур хатын-кыз күлмәкләре, ирләрнең киҗе камзуллары, чигүле сөлгеләр эленгән. Өстәлгә бизәкле ашъяулыклар җәелгән. Гадәттә җиткелекле яшәгән татар гаиләсендә самавыр була. Әмма бу авыл ярлырак иде; мулла самавыры безнең белән өйдән-өйгә сәяхәт итте. Татар авылында өй борынча кунак булуыбызның соңы мулла өендә тәмамланды. Мондагы сөй-хөрмәт инде Казандагы татарларныкына охшаш: кура җиләге кагына йөзем, өрек-күрәгә, караҗимеш, пестә чикләвеге (фисташка) өстәлә».*

***Карл Фукс.***
***Казан һәм татарлар турында***
***(Казан, 1844)***



ТАТМЕДИА Республика агентлыгы җитәкчесе урынбасары Эдуард Хәйруллин чәй сервизы ясау идеясе белән мөрәҗәгать иткәч, шушы хатирәләр күз алдыннан узды, шушы фактлар һәм фикерләргә таянып эшкә керештем. Бу гаҗәеп кызыклы тәкъдим иде. Сервизның Санкт-Петербургның иң яхшы Император заводында нәзакәтле «сөяк фарфорыннан» ясалачагы да алдыма яңа бурычлар куйды. Бу завод белән Мәрҗани фонды заказы буенча «Алтын һәм көмеш Болгар», Мәскәү Җәмигъ мәчете заказы буенча «Алтын манаралар» чәй сервизлары ясаганда эшләгән идем.

Сервиз ТАССРның 100 еллыгына багышланган, ләкин безнең 1000 еллык тарихыбыз бар – сервиз декорында шушы бай мирасны чагылдыру минем өчен зур әһәмияткә ия иде. Төп бизәк ясалгач, ә сервизның һәр предметында төрле бизәк, мин аның XVI гасырда Казанның зәркән осталары ясаган данлыклы «Казан бүреге» орнаментларын хәтерләтүен аңладым. Сервизның тышкы кыяфәтендә чагылган бу охшашлыкта буыннар хәтере саклануын күрдем – ул хәтер безнең хисләрдә һәм образларда чагыла. Сервизны без «Тантана» дип атадык.

P.S. Проектка компьютер ярдәме күрсәткән Җәмил Федотовка зур рәхмәтемне белдерәм.



Фоторәсемнәр Наилә Кумысникованың шәхси архивыннан

*Евгения ШЕМЕЛОВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге методисты*

# Хан кызы серләре

***Бизәнү әйберләре дөньясында «art jewelry» дигән төшенчә бар. Сүз зәркән осталары тарафыннан асылташлар яки кыйммәтле минераллар кулланып, кабатланмас стильдә, бердәнбер данәдә ясалган бизәнү әйберләре турында бара. Ювелир һәм дизайнер Ләйсән Халикова үз исеме белән аталган «LEYSAN KHALIKOVA» проектында нәкъ менә шундый сәнгать әсәренә тиң эшләнмәләр иҗат итә. Аның коллекциясе «Татарская принцесса» / «Хан кызы» дип атала.***

Һәр бизәнү әйберендә халык тарихы чагыла – коллекциянең уникальлеге шунда. Зәркән эшләнмәләрендә Казан ханлыгы, Идел Болгары, Алтын Урда чорын тоябыз, татар мифологиясендәге гаҗәеп затларны очратабыз, данлыклы Ефәк юлы аша халыклар бердәмлеген күзәтәбез.


Ләйсәннең тарих белән кызыксынуының сәбәбе бар – ул мәшһүр тарихчы һәм археолог Альфред Хәсән улы Халиковның оныгы. Аның бу проекты да Казан һәм Татарстан тарихында данлы эзен калдырган бабасының якты рухына багышлана. «Бабаемның Болгардагы иң билгеле археологик табышлары арасында алтын үрдәк сурәтле борынгы чигә асмалары бар, – ди Ләйсән. – Бу – берьюлы өч дөньяда яшәүче зат турында, төрки халыкларның төп мифларының берсе, магик символ, саклагыч бөти. Әлеге алтын үрдәк – безнең брендның логотибы. Брендның девизы: «Бөек үткәнебезне белү бөек киләчәккә илтә!»


Бервакыт Ләйсән төшендә Сөембикә ханбикәне күрә. Ханбикә аңа үз әмере белән Кабан күле төбенә яшерелгән хәзинә турында сөйли. Ә иртә белән Ләйсән остаханәсендә эскизлар ясарга керешә – бизәнү әйберләре шулай барлыкка килә башлый. Зәркән остасы үз стилен «Татар ренессансы» дип атый. Һәр бизәнү әйберенең үз исеме, тарихы һәм рухи көче дә бар. Зирәк ханнар белән кыю сугышчылар һәм гомумән үз җирен данлаган ирләре артында торган хатын-кызларга багышланган «Хан кызы» чылбыр асмасы, «Панджара тәрәзәсе» йөзеге, «Елан күзләре» алкалары, Зөләйха ханбикәнең әсир егет Йосыфка булган мәхәббәте турындагы риваятьне хәтерләтүче «Зөләйха көзгесе» балдагы, «Алтын тәхет» балдагы (Болгар шәһәрен шәрыкъ чыганаклары шулай атаган), «Умай алиһә» балдагы (төркиләрнең төп алиһәсе) һәм башка күп эшләнмәләр.


GRANDE TARTARIE
LEYSAN KHALIKOVA
tatar princess collection

Премиум сегментындагы зәркән бизәнү әйберләре: рубиннар, бриллиантлар, сапфирлар, турмалиннар, зәбәрҗәтләр белән бизәлгән чылбыр асмалары, балдаклар, колак алкалары беренче карашка ук сихерле. «Зәркән осталыгына мөмкин булган бөтен җирдә дә өйрәндем. Һиндстанда базар мәйданнарында эшләүче урам зәркәнчеләренең эшләрен күзәттем, Непалда 300 ел дәвамында король зәркәнчесе булган династия дәвамчыларыннан дәресләр алдым...», – ди Ләйсән.

Ул үз иҗатында сирәк очрый торган чын асылташлар гына куллана. Аларны үзе сәяхәт иткән урыннардан – планетаның төрле җирләреннән алып кайта. «Металл эшкәрткәндә Көнчыгыш таш кисү һәм зәркән сәнгатендә «җәли» дип аталган уникаль




◆ ***Зирәк акыллы ханнар, кыю гаскәриләр, үз җирләрен данлаган ирләре артында торган хатын-кызларга, ханбикәләргә һәм хан кызларына, аналарга, апаларга – бу җиһанның, гүзәллеге белән сокландырган һәм илһамландырган, авыр чакта таяныч була алырдай кызларга багышлана.***

***Опаллар, рубиннар, сапфирлар, алтын, көмеш.***

◆ ***Х гасырда Идел буе Болгар дәүләте барлыкка килә. Идел белән Кама кушылган урында – стратегик һәм сәүдә ягыннан әһәмиятле урында урнашкан Болгар шәһәре Идел буе халыклары өчен генә түгел, Көнчыгыш Европа тарихында да зур роль уйный.***


***Рус елъязмачылары аны – Бөек Болгар, шәрыкъ чыганаклары Алтын тәхет дип атый.***


***Иолит, сапфир, алтын, көмеш, гравировка.***

техниканы кулланам. Россиядә беркем дә диярлек ул техника белән эшләми», – дип кайбер серләрен дә ача.

Заказларга килгәндә, аларны Ләйсән проект үсеше юнәлешендә булган очракта гына ала. Мәсәлән, Идел Болгарында Ислам кабул ителүгә 1100 еллыкка багышлап чылбыр асмасы ясалган. Металлга каллиграфия белән Коръән сүзләре язылган: «Доброе здравие, да счастье, да благополучие обладателю сего!»

«Хан кызы» коллекциясе зиннәтле каталог белән тәкъдим ителә. Бизәнү әйберләренең үзләре кебек каталогы да сәнгать әсәренә тиң – ул иҗат икән һәр эшләнмә аутентик, антиквар предметлар өстендә төшерелгән. Әйтик, борынгы калфактан кадрга өч энҗе бөртеге генә керергә мөмкин,




◆ ***Панджара – тәрәзләрнең бизәкле рәшәткәсе. Ул Борынгы Болгарның Кара пулатында тәрәзләрне бизәгән. Казан ханлыгында сарайларның һәм байларның зиннәтле йортларының тәрәзәсен бизәү өчен төсле пыяла куелган.***

***Казан таш сарайлары һәм биек манаралы мәчетләре белән дан тоткан, хан төрбәләре зиннәтле итеп бизәлгән.***

***Аквамариннар, зөбәрҗәтләр, сапфирлар, алтын, көмеш.***


◆ ***Кол Гали – Урта гасырның бөек шагыйре, болгар шигърияте нигез салучы. Әдәбият галимнәре шәрыкъ Ренессансын аның исеме белән бәйли.***

***Иҗатының югары ноктасы булган «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә Кол Гали Зөләйха ханбикә белән әсир егет Йосыф турындагы данлыклы риваятьне тасвирлый.***

***Опаллар, турмалин, алтын, көмеш.***


әмма бу ниндидер үзенчәлекле бер нурланыш барлыкка китерә. Каталог шрифтын да тәҗрибәле каллиграф иҗат иткән.


«Сәнгать ул халыкның дөнья аренасындагы имиджы. Үз бурычымны татар халкының мәдәни мирасын һәм традицияләрен популярлаштыру һәм актуальләштерүдә күрәм. «Хан кызы» проекты аша татар мәдәниятенең матурлыгын җир шарына






◆ ***Казан шәһәре гербында таҗлы аждаһа – еланнар патшасы Зилант сурәтләнгән. Башындагы таҗы аның югары дәрәҗәсен аңлата. Зилант татарча елан сүзеннән алынган. Казан шәһәре барлыкка килү турындагы риваятьтә кала салынасы урында еланнар яшәве һәм аларның патшасы Зилант булуы бәян ителә.***

***Бриллиантлар, кианитлар, алтын, көмеш.***










житкерәсем килә. Әлеге бизәнү әйберләрен алган кешеләр бу җирлек рухының бер кисәген үзләре белән алып китүләрен әйтәләр, алар аны, нәселнең кыйммәтле әйбере буларак, буыннан буынга күчерергә хыяллана», – ди Ләйсән.

Ләйсән Халикованың калган эшләрен @leysankhalikova аша кереп карый аласыз




◆ *Казан шәһәренең хәзерге гербын «Казан бүреге» – хан таҗы бизи. Таҗ шәһәрнең борынгы традицияләре булган территорияләрнең башкаласы статусына ия булуын күрсәтә.*

*Алтын һәм көмештән ясалган, асылташлар белән бизәлгән һәм кеш тиресе белән каймаланган таҗ-бүрек – татар зәркәнчелек сәнгатенең иң затлы әсәрләреннән берсе.*

*Бүрекне 90 каратлы сары сапфир бизи.*

*Тай энҗесе, һинд турмалины, алтын, көмеш.*

*Эльвира МОЗАФФАРОВА,*
*журналист*

# БАЛЫК БИСТӘСЕН *Америкага таныткан челтәр*

***Күз явын алырлык итеп нечкәләп үрелгән челтәр әйберләр элек-электән зәвыклы саналган, югары бәяләнгән. Таякчыклар белән челтәр (кружева) үрү – борынгыдан килгән һөнәр. Петр I реформалары башлангач, челтәрдән үрелгән киемнәр модага керә, Россиядә бу эш белән ныклап шөгыльләнүче үзәкләр барлыкка килә башлый. Аларның берсе Балык Бистәсе районында урнаша. XIX гасыр уртасы XX йөз башында анда йөзләгән хатын-кыз челтәр үрә. Аларның кул эшләре районны дөньяга таныта. Соңрак, дөньяның асты өскә килгән сугышлар чорында, челтәргә ихтыяҗ калмый, буыннар алмашынгач бу кәсеп акрынлап онытыла.***



12 ел элек Балык Бистәсендә бу һөнәрне кабат торгызалар. Рәмзия Фәттахова район мәдәният йорты каршында «Яңарыш» студиясе оештыра – анда өлкән яшьтәгеләр, балалар да челтәр үрү серләренә өйрәнә. Балалар иҗат үзәгендә үсмерләргә дәресләр бирә. Киләчәктә мәктәптә аерым түгәрәк булдырырга хыяллана.

– Районыбызның горурлыгы булган һөнәрнең онытылуын теләмим, – ди ул. – Балык Бистәсе кызлары үргән челтәр үзенчәлекле бизәкләре, нәзәкатьле булуы белән аерылып торган. Районда элек бу һөнәргә өйрәтә торган мәктәп булган, артель сафка баскан. Балык Бистәсендә аршынлы челтәрләр һәм «чылбырлы челтәр» (цепное кружево) үрелгән. Безнең район челтәрләре Мәскәүгә, Петербургка, хәтта Америкага кадәр таралган. Казан мәдәният һәм сәнгать университетында укыган чакта мин челтәр үрүне үзләштердем. Шуннан соң бу һөнәр югалмасын өчен мәдәният йорты каршында челтәр үрү түгәрәге ачарга булдым. Максатыбыз – онытылып барган һөнәрне киләчәк буынга тапшыру. Хәзер төрле күргәзмәләрдә, милли бәйрәмнәрдә эшләребезне тәкъдим итәбез, – ди Рәмзия Фәттахова.


Рәмзия Фәттахова

Рәмзия Фәттахова Балык Бистәсе районының Олы Елга авылыннан. Кечкенәдән тегәргә, чигәргә, бәйләргә өйрәнгән. Күн мозаикасы буенча да тәҗрибәсе бар – моңа 40 нчы һөнәр училищесында өйрәнгән. Алга таба укуын Казан дәүләт мәдәният институтында дәвам иткән – халык һөнәрчелеге белгечлеген алган.

– Балык Бистәсе районының Туган якны өйрәнү музееннан алынган мәгълүматлар буенча, районда иң беренче булып, XVII гасырда Новгород өлкәсеннән күченеп кайтучылар челтәр үрә башлый. Балык Бистәсендәге челтәр үрү һөнәрчелеген XIX гасырда алпавыт кызы Екатерина Донаурова үз иганәчелегенә ала. Челтәр үрү сәнгатен үстерү өчен ул зур көч куя, – ди Рәмзия.

Челтәр үрү – шактый сабырлык, төгәллек, җитезлек сорый торган эш. Гадәттә, челтәр үрү өчен мендәрчек-валик һәм җиде-сигез агач таякчык кирәк. Аларны «коклюшка» дип йөртәләр. Бары тик сыйфатлы җитен җепләр генә файдаланыла. Челтәрне үрә башлар өчен эскиз кирәк. Рәсем ясау аерым осталык сорый. Үзенчәлекле үрнәкләр булдыру фантазия таләп итә. Рәмзия Фәттаховада 70 ел элек үрелгән челтәр үрнәкләре дә саклана. Рәсем контуры буенча энәләр кадыйлар, аннары җеп белән үрә башлыйлар. Кызлар эшләгәндә, таякчыклар бәрелгән тавышлар гына ишетелә.

– Мондый ысул белән челтәр үрү ыргак белән бәйләгәнгә караганда тигезрәк, нәзакатьлерәк була. Алар сатып алучыны озак еллар сөендерәчәк, челтәрләр бик чыдам, – ди Рәмзия Фәттахова.

Кулмәккә бер яканы үрү өчен генә дә айга якын вакыт сорала. Шуңа да мондый зәвыклы эшләнмәләр бик кыйммәт








«Яңарыш» студиясендә








бәяләнә, иң арзаны 1 000 сумнан башлана, үрелгән җиләннәр 300 мең сумга җитәргә мөмкин. Эшләнгән эш әрәм ятмый – сатып алучылар бар, кызыгып интернет аша да заказ бирәләр.

Әлеге кул эшләнмәләре белән кызыксынучылар елдан ел артып бара икән. «Яңарыш» студиясендә шөгыльләнүче кызларның эшләрен Алабугада уза торган Спас ярминкәсендә тәкъдим итәләр, челтәрдән үрелгән киемнәр киеп, төрле чараларда мода күрсәтәләр. Кызларның эшләре төрле бәйгеләрдә югары бәя ала, яңаларыннан – «Мәдәни код – яшәү стиле» фестивалендә дипломга лаек булганнар. Калфаклары, кулъяулыклары берничә ел рәттән «Татарстанның иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» каталогына кергән. Рәмзия Фәттахова «2021 ел һөнәрчесе» исеменә лаек булган: ике эше республиканың иң яхшы сувенирлары исемлегендә урын алган.

Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивы һәм Салават Камалетдинов, Эльвира Мозаффарова фоторәсемнәре

# Бергәләп бизибез!



*Луиза ВАФИНА,*
*Әтнә, Күәм авылы,*
*әйдәп баручы китапханәче*

# КАЛАТАУДА АЙЛЫ МАНАРА, ТАРИХЫБЫЗ ШУННАН БАШЛАНА…



***Ашыт елгасының Күәм авылыннан ерак булмаган биек уң ярындагы агачлы өлешен Әтнә ягы кешеләре Кала тавы дип йөртәләр. Кала тавына бу якларда татар халкы яшәгән иң борынгы, изге урын буларак киләләр.***

Археология-тарих фәнендә Кала тавы Әйшияз шәһәрчеге буларак билгеле. Дөресрәге, Кала тавы дип йөртелгән урында истәлекле, изге тарихлы өч урын бар. Күәм авылыннан көньяк-көнбатышка таба, Ашытның уң як биек ярында, агачлыкларга кадәр Әйшияз шәһәрчеге зираты урнашкан. Халык телендә ул «Хан зираты» дип йөртелә. Зиратта язусыз өч кабер ташы бар. Ташларның биеклеге 80 см, киңлеге 60 см, калынлыгы 25 см тирәсе. Бер кабер ташы сынган, җирдә ята. Соңгы елларда кабер ташлары янына тимер чардуган һәм «Габдулла улы Әйшәхан. 960-985 елларда яшәгән һәм дәфенлән-




гән» дип язылган таш куелган. 1956 елда бу зиратта ике каберне археолог Н.Ф. Калинин казып караган. Кабердәге гәүдә, башын көнбатышка куеп, битен төньякка каратып, җилкәсендә яткырып җирләнгән. Янында әйберләр булмаган. Галимнәр XVI гасырга караган мөселман зираты дигән нәтиҗәгә килгән. «Хан зираты» дип йөртелү дә зиратның мөселманнарныкы икәнен искәртеп тора. Бәлкем, бу зиратта татарлашкан марилар күмелгәндер дигән фаразлар да бар. *(Археологические памятники Татарской АССР. Казань, 1987, 101 стр.)*

Күәм авылының ветеран колхозчысы Илсур абый Мөхәммәдиев истәлекләре дә казу эшләренең булганын раслый: «1956 еллар тирәсендә Николай Калинин безнең авылга кайтып, «Калатау асты» дип аталган җирдә казу эшләре алып барды. Ул чакта бу урынны «крепость» дип йөртәләр иде. Калинин бу урында крепость булганмы, юкмы – шуны тикшерде. Без – үсмер малайлар, казу эшләрендә катнаштык: аның картасы буенча казу эшләре алып бардык. Беренче зур капка, аннан соң кечкенә капка урыннарын таптык, балчык астында ярым күмерләнгән агач баганаларга юлыктык. Аның яныннан юл төшеп китә иде. Калинин аны суга төшә торган юл дип аңлатты», – дип үткән елларны искә ала ул.

«Хан зираты»ндагы өч кабер ташыннан 150 метр көнбатыштарак, Әйшияз шәһәрчеге урнашкан. Шәһәрчек өчпочмак формасында. Өчпочмакның очлы почмагы көньякка – Ашытка таба караган. Төньяктан мәйданчык ике рәт вал (балчык өеме) һәм чокыр белән сакланган. Тышкы валның озынлыгы – 86, киңлеге – 3-4, ә биеклеге 0,5-1 метр. Валның дүрт урынында тирәнлеге – 1, киңлеге – 2-4 метр булган чокыр ясалган. Тышкы вал, чокыр, керү юллары бүген дә әйбәт күренә. Тышкы валдан 44 метр эчтәрәк 38-45 метр озынлыкта икенче вал бар, анысы начар сакланган. Эчке һәм тышкы вал арасындагы трапеция формасындагы тигез мәйданчыкның озынлыгы – 60 метр, киңлеге – 38 метр. 1956 елгы археологик казу эшләре вакытында керамик әйберләр дә табылган. Галимнәр аларны безнең эраның 1 меңьеллыгы уртасына хас дип билгеләгән.

## РИВАЯТЬЛӘР

Авыл халкында әлеге изге тарихи урыннар белән бәйле риваятьләр саклана. «Кала арты» атамасының килеп чыгышына бәйле риваять болайрак. Имеш, Күәм буласы урында безнең ерак бабаларыбыз Казан каласын кормакчы булган. Бирედә челтерәп аккан чишмәләр, табигать нигъмәтләренә бай киң болыннар, куе урманнар җәлеп иткән аларны. Ул заманда Ашыт суы да киң – 1,5-2 чакрым чамасы була. Аның суында сал белән ак чыршыларга хәтле агыза торган булалар. Крепостьның көньягында Ашыт суына төшеп менү өчен дамба салынган. Шул чор белгечләренең: «Су юлының киләчәге юк, ул саегачак», – дигән фаразлары шик салган, күрәсең, зур шәһәр кору уе булган бабаларыбыз киңрәк елга буена утыруны кулай күреп, бүгенге Казан урынына барып урнашкан. Аларның бу яклардагы эзе булып, «Кала арты» атамасы калган. Риваятьләргә уйдырма кушылса да, бирედә каланың төзелә башлавы, хәрби шәһәрчек булуы хак. Бу хакта галимнәр дә язып калдырган. Мәсәлән: «...Ул урында (Кала тавы) соңгы заманга чаклы куе урман булган. Хәзерге заманыбызда да әле чиксез «Иләт» урманы күренеп тора...» *(Шиһабетдин Мәрҗани. Мөстәфаделәхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан, 1989, 160-161 б.).* Ш. Мәрҗани Кала тавы ислам мәмләкәтенең чиге булып, бервакыт чирмешләрдән сакланып өчен, кальга буларак кына хезмәт итмәдеме икән, дигән фикерне дә әйтә. Тарихчы С.М. Шпилевский *(Древние города и другие булгаро-татарские памятники*



*в Казанской губернии. Казань,1877)* Әйшияз шәһәрчеге валлары кирпеч ишелүдән барлыкка килгән икәнен дә әйтә. Димәк, кайчандыр валлар өстендә кирпеч стена булган, дип әйтергә нигез бар. Ә мари тарихчылары *(Очерки истории Марийской АССР. Йошкар-Ола,1965)* Әйшияз шәһәрчеге Мари җирләренең көньяк чигендә XIV гасырда болгарларның төньяккарак үтеп керүенә киртә ясау өчен төзелгән кальга булмадымы икән, дигән фикерне дә җиткерә. Олы Бәрәзә авылыннан Галиулла Заһидуллин (1874-1947) язып калдырган «Олы Бәрәзә тарихында» да Кала тавы искә алына. *(М. Әхмәтҗанов. Нугай Урдасы. Казан, 2002, 282 б.)* «Вәткә ханлыгы Болгар ханлыгына баш иеп, салым түләп торганнар. Күбрәк сугыш фронтлары Өҗем басуларындин башланып, әчкә таба кереп дугувурлашып, солых ясар булганнар. Бу Кала тавында канаулар казып сугышканда, җылдан артык сугыш ясап, Вәткә губернасы Басалай авылы урнында вәкәләрне җиңеп, солых шарты төзегәннәр...» Татарстан АССР тарихының I томында *(Казан, 1959, 12 б.)* бирелгән археологик картада бронза гасырында Казан тирәсендә кешеләр яшәгән һәм шул культураның истәлекләре табылган урын буларак, Әйшияз шәһәрчеге күрсәтелгән. Татарстанда бронза гасыры безнең эрага кадәр 2 нче меңьеллыкка туры килә. Шуннан, Кала тавының никадәр борынгы урын икәнен чамаларга була.

### ИЗГЕЛӘР ЗИРАТЫ

Кала тавында урнашкан тарихи урыннарның тагын берсе – Изгеләр зираты. Ул Әйшияз шәһәреннән 400 метр чамасы көнбатыштарак, урман эчендә урнашкан. Хан дин әһелләрен кирмәннән көнбатыштарак булган шушы имәнлеккә җирләтә. Соңрак бу изгеләр зиратына ислам дине әһелләре дә җирләнә. Шунлыктан бу урынны «Әүлияләр каберлеге» дип атыйлар.

Изгеләр зиратына кергәч шушы язуны укырга була: «Бүгенгәчә исеме төгәл сакланмаган ханның дин әһеле Ирәмәли балалары, Сөләйман хаҗи, мулла Таҗетдин, кызлары Гайшәбикә һәм Хәнифәбикә абыстайлар һәм дә 5 сабый кыз бала шушында дәфенләгән (якынча 960-985 еллар). Шушы урында имән утыртылган». Чыннан да, Изгеләр зиратында кабер өстенә утыртылган колач җитмәслек юан имән агачы бар. Аны «меңьяшәр имән» диләр. Агачның яшен Мәскәү гуманитар академиясе профессоры, галим Борис Фатыйх улы Усманов (чыгышы белән Күәм авылыннан) тикшерә һәм раслый.

Бу зиратта гаҗәеп бер хис биләп ала: борынгы бабаларыбыз үткән юллардан йөргәндәй буласың. Кала тавының иң биек ноктасына менеп, аста көмеш тасма булып кына күренгән бормалы Ашыт суына, күз күременә кадәр җәелгән болыннарга карап, үзеңне гүя борынгы Болгар чорына әйләнеп кайткандай хис итәсең... Йөз, мең еллар элекке кебек, бүген дә җир куеныннан бәреп чыккан Изге чишмә, тау битен ертып, Ашыт суына җан өстәргә ыргыла. Борынгы каберләр өстендә бүген дә ерак гасырларның шаһитләре булган имәннәр шаулый.

Шушы Калада мең ел элек яшәгән борынгы бабаларыбызның каны тамырларда аккангамы, Күәм һәм әйләнә-тирәдәге башка авылларның халкы Изге чишмәгә сукмакны беркайчан да суытмый. Тау итәге астыннан кача-поса Әүлияләр каберенә килеп дога кылган чаклар, шөкер, тарихта калды. Бүген борынгы зират тимер рәшәткә белән әйләндерелгән, кешегә ял итү урыннары көйләнгән. Биредә иртә яздан кара көзгә кадәр мосафирларны очратасың.

## ӘЛӘШӘ БӘЙРӘМЕ

Ел саен июньнең беренче җомгасында – уҗымнар тишелеп чыккан, сыерчык бала очырган вакытта – «Изгеләр зиратында» Әләшә бәйрәме үткәрелә.

«Әләшә» – элек-электән үткәрелеп килгән җыеннарның бер төре, аксакаллар әйтүе буенча, ул Калатау тирәсендә генә үтә. Бу көнне авыл халкы Калатауга төшеп, «Әүлияләр каберлеге»ндә дога кылган, Ходайдан мул уңыш һәм елның тыныч-имин булуын ялварып сораган.

Совет власте килгәч Әләшә бәйрәме үзгәргән: өлкәннәр дога кылгач, яшьләр анда кичке уен үткәргән. Әмма дингә һөҗүм башлангач, бу йоланы дини бәйрәмгә санап бөтенләй тыйганнар. Ләкин авылдашлар гасырлар буе тоткан диннәрен һәм йолаларын онытмаган: кача-поса булса да, Калатауга менеп намаз укыганнар, «Изгеләр чишмәсе» суыннан авыз иткәннәр. Сиксәненче еллар азагында гына Күәм картлары Әләшә бәйрәме турында иркенләберәк сөйләшә башлый.

1994 елдан авылыбыз имамы Мөбәрәк ага Галиев һәм күмәк хуҗалык рәисе Әгъзәм Бәкер улы Борһанов инициативасы белән Әләшә бәйрәме зурлап уздырыла башлый. Өлкәннәрне алып килү өчен автобус бирелә, «Әүлияләр каберлеге»нә җитәрәк сул як аланда бабайларга намаз уку өчен җәймә җәелә, халык өчен коймак, чәй әзерләнә. Килгән кешеләр дә күчтәнәчләре белән табынга кушыла.

Элек халык бирегә иген кыры уртасына салынган сукмак аша килә торган була. Мең газап белән чишмәгә төшеп менә, чөнки таудан төшү бик читен, аяклар тая, кызыл балчык ишелә. Төшеп җитеп, кабат үргә менүләре дә әҗәл белән бер. Уфтансалар да, авыр булса да, халык башкасын көтми. Зират, зират инде, ничек бар, шулай кабул итә. 2005 елда бәйрәмгә килүчеләр шатлыклы күз яшьләрен сөртеп, район хакимияте башлыгы Габделәхәт Гыйлемхан улына рәхмәт укыйлар. Чөнки Изгеләр каберлеген торгызу һәм яңарту өчен хакимият ярдәм күрсәтә. Торгызу эшләре Әгъзәм Бәкер улы җитәкчелегендә башкарыла. Иң элек каберлеккә барырга юл салына. Зиратка керү юлында мемориаль такта куелып, «Әүлияләр каберлеге»нең тарихы языла. Чишмәгә төшү өчен тимердән 162 басма ясалып, тотынып менәр өчен торба сузыла.

Ә иң ошаганы: басмалардан менү юлында туктап ял итәр өчен өч-дүрт җиргә утыргычлар куела. «Изгеләр чишмәсе» кызыл кирпечтән бик матур итеп эшләнеп, ак калай түбә астына кертелә, ябарга капкачы да, янәшәсендә улагы да, савыт-сабасы, чүмече дә куела. Дини бәйрәм елдан-ел камилләшә, ул хәзер олылар гына бәйрәме түгел, балалар да кулларын догага күтәрә.

Әйе, «Әләшә» – ул җир белән күкнең аңлашу көне. Арадашчысы – изгеләр рухы. Нигезендә Ходайга ышану, изгеләрне олылау, буыннан-буынга күчкән гадәтне саклау ята. Бәйрәмнең онытылмыйча, һәр елны югары дәрәҗәдә үтүе горурлык хисләре уята, татар халкы үз рухын югалтмас дигән өмет уята. Туган ягыбызның матурлыгын, изгелеген, аның гореф-гадәтләрен, йолаларын килгән кунаклар күреп, сокланып китә.

Автор фоторәсемнәре

# Кендек әбиләре

Гаиләдә бала туу – шатлыклы вакыйга. Җаннан җан аерылып, сабый баланың дөньяга аваз салуы – үзе бер могҗиза. Бу уңайдан безнең якларда да бик матур гореф-гадәтләр булган, кайберләре бүген дә сакланып калган.

Әниемнең сөйләве буенча, Дәвеш авылында шәфкать туташларын алыштырырлык кендек әбиләре яшәгән. Бу һөнәр буыннан-буынга күчкән. Элек хатын-кыз бала табарга авырый башлагач, тиз генә кендек әбисен чакыртканнар. Хәбәр булуга ук тәҗрибәле, догалы әбиләр җыенып, тәһарәтләнеп, кирәк-яракларын алып, бәби табарга булышырга, сабыйны кабул итеп алырга дип килеп тә җиткәннәр.

Әнием үзенең кендек әбисен бүген дә хәтерли. «Гадән әбиең Гыймадиева кечкенә генә карчык иде. Ул – минем кендек әбисе. Гадән әби дөньяга килергә булышкан балалар авыл тулы дип сөйлиләр иде. Камыр ашлары пешергән саен: «Бер кечкенә күмәчне кендек әбиеңә илтеп кил әле», дип әйтә торган иде әнием. Күз тиеп елый башласам да, шул әбинең берәр чүпрәк кисәген алып кайтырга куша иде», – дип искә ала аны.

Ул заманнарда авыллар зур булган, балалар да күп туган. Бер кендек әбисе генә барысына да өлгермәгән. Авылның югары очында яшәүче Кәримә абыстай да бала тудырганда булышучы вазыйфаларын башкарган. Кендек әбиләре, баланың кендеген кисеп, аны җыеп куярга кушканнар. Ул сандыкның кеше кулы тими торган почмагында сакланган. Бала елый, көйсезләнә башласа, догалар укып өшкергәннәр, шул кендек белән имләгәннәр, шифасы тия торган булган.

Бала туган вакытка мунча өлгертеп куйганнар. Мунчада кендек әбисе ананы «Бала мунчасы»на керткән, эчләрен сыпырып урынына утырткан. Яңа гына бала тапкан ана өч көн рәттән мунча керсә, авыррак тапканнар берәр атна мунча кергән, кендек әбисе дә килеп, эчен урнаштырырга булышкан. Яңа гына бала тапкан ана юынган мунча шифалы саналган, шуңа күрә ул көнне башка туганнар да керергә тырышкан.



«Балага исем кушу йоласы». Алия ШИҺАПОВА рәсеме. Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы

Кендек әбиләре авылда бик зур хөрмәткә ия булган. Иң беренче күчтәнәчне дә аларга бирергә, булышырга тырышканнар. Бигрәк тә нәсел дәвамчысы, имана җире бирeләчәк (элегрәк имана җирләрен ир балаларга гына биргәннәр) ир бала туса, күчтәнәчне әти кеше бер дә кызганмаган.

Бала тапкан хатынга, өзлегеп китмәсен дип, бәби чәйләре, камыр ашлары китерә торган булганнар. Бу гадәт хәзер дә саклана: туганнарга, тирә-күршедә бала табучыларга бәби чәе кертәләр. Бәби чәе китерү – бик савaплы эш.

Бүгенге көндә балага исем кушу йоласы да элеккесеннән әллә ни аерылмый. Мул табыннар әзерләп, мулланы һәм якын туганнарны чакырып, балага исем кушалар. Сабыйны, мендәргә салалар, мулла азан әйтә, тиешле догаларын укып, баланың колагына кушылачак исемен, әтисенең исемен пышылдый. Аннары мул табын артында бергәләп чәй эчәләр.

Хәзер инде без кендек әбиләре турында әниләрдән, дәү әниләрдән ишетеп, китаплардан укып кына беләбез. Ә әби-бабаларыбыз хәзер дә кендек әбиләренә атап дога кыла. Димәк, әле бүген дә аларга карата хөрмәт бар. Гореф-гадәтләребезне онытмыйча, горур халык булып яшәсәк иде.

**Гөлнара ХӨСӘЕНОВА,**
**Апас, Дәвеш мәктәбе укытучысы**

# «Качману» ашы

Бу елның гыйнвар аенда Мамадыш районы Ылыя керәшен авылында «Качману ашы» уздырдык. Нәрсә соң ул «Качману», дисәгез, кач + ману сүзләреннән кушып ясалган. Бу – Иисус Христосның суга чумдырылган көне – 19 гыйнварга туры килә. Ул көнне су изгеләндерелә, аның файдасы, шифасы, терелтү һәм авыруларга ярдәм итү үзлеге барлыкка килә. Ә Качману бәйрәме күңел ачу, кунакка йөрешүләр белән дәвам итә.

Хәтеремдә, әле мин кечкенә вакытларда, безнең авылда, әби-бабайлар, өлкән яшьтәгеләр мал суйганнан соң, өйдән-өйгә ашка йөриләр иде. Хәзер мондый мәҗлесләр, туганнар, дус-ишләр белән җыелышып утырулар әкренләп югалып бара. Менә шушы матур гадәтне искә төшерү, яшь буынга үрнәк күрсәтү максатыннан, өлкән яшьтәге түтиләр-дәдәйләр белән сөйләшеп, оештырдык та инде «Качману ашы»н.

Бөтен йоласына туры китереп уздырган бәйрәм ашы бик күңелле үтте. Башта милли керәшен күлмәкләрен киеп, үзебезнең авыл җырларын җырлап, йорттан-йортка кереп, урам әйләндек. Һәр өйгә кергәндә йорт хуҗаларына матур теләкләр ирештердек, нигезнең бәрәкәтле, мал-туарларының мулдан булуын теләдек, шуларга атап, икмәк бирдек.

«Качману ашы» мулдан әзерләнгән табын артында дәвам итте. Барлык туганнар, күрше-күлән, дус-иш җыелды. Һәр керәшен мәҗлесендәге кебек уен-көлке сөйләшеп, керәшен халкының үзенчәлекле җырларын җырлашып кинәндек. Билгеле инде, керәшен халкының дан тоткан пирмәнкәсе табын күрке булды. Пирмәнкәне чыгарганда җырланыла торган махсус җырлары да бар керәшеннәрнең. Шуларны җырлап, кунакларны сыйладык:

*Бүген эшләгәннәрем шул булды,*
*Пирмәнкәләр булды ла бөккәнем.*
*Капка төпләренә чыга керә,*
*Сез булдыгыз минем лә көткәнем.*

*Атларымны җиктем дә мин киттем,*
*Барып җитәрмен диеп Кирмәнгә.*
*Сез дә туганнарым килә дигәч,*
*Пешереп лә йөримен пирмәнкә.*

*Ишек алларында утын җардым,*
*Утын җарулары ла тирләтә.*
*Табыныбыз мулдан булсын әле,*
*Сыйланырга куйыек ла пирмәнкә.*

Пирмәнкә артыннан тутырма чыгарылды. Бу ризык та керәшеннәрдә кунак каршы алганда чыгарыла.



**Ишек алдында ипи бирү**



Урамнан җырлап бару

*Әйдәгез туганнар, без җырлыек,*
*Кунакларда тик лә утырма.*
*Табыннарның олы бу ризыгы,*
*Өстәлләргә куйыек тутырма.*

Бәйрәм ашында менә шушындый борынгы җырларыбыз яңгырап торды. Әле ярый болары халык хәтерендә яшәп калган! Кызганыч, күбесе онытылган.

Керәшеннәрнең кунак бәйрәмнәре бик үзенчәлекле. Алар кунакта сүз алып сөйләшеп утырмаган, әйтәсе сүзен җыр белән генә җиткергән, такмак әйтә-әйтә биегән. Без дә шушы гадәтләрне сакларга тырышабыз.

Бу гадәт-йолалар алга таба да сакланырмы? Яшьләребез традицияләребезгә тугры калырмы? Без үрнәк күрсәтсәк калыр дип ышанасы килә. Яхшыга өметләник.

**Роза ГАЛКИНА,**
**Мамадыш районы мәдәният йорты методисты**

Роза Галкина һәм Борис Мельников фоторәсемнәре




Качману ашын башлап җибәрү

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

# ХАЛЫК ИҖАТЫНДА *дини-мифик йолалар*

***Татар халкында XVIII йөзнең популяр дастаннары арасында «Каһарман Катил» яисә «Каһарман» исеме белән мәгълүм бик күркәм эпос бар. Идел-Урал буе татарларында язма формада таралган әлеге маҗаралы-героик дастанның берничә варианттагы кульязмалары Казанның төрле фәнни үзәкләрендә саклана, ә XX йөз башында ул Казан типографияләрендә берничә кат басылып та чыга.***

Әлеге әсәрнең исеме тарихта XX гасырның егерменче елларыннан ук билгеле булган, әмма халыкта сакланган вариантларын табып алып, кабат басылып чыгуы XX йөз ахырында гына башкарылды. «Каһарман Катил»не 1918 елгы гарәп язулы басмасы нигезендә текстологик эшкәртеп, фәнни әйләнешкә кертүче – әдәбият галиме М.И. Әхмәтҗанов. Ул дастанның борынгы кульязмаларын эзләп тапкан, текстларны укып-өйрәнеп, телен бүгенге сөйләмгә якынайтып, әсәрне аерым китап рәвешендә бастырып та чыгарган. «Каһарман Катил (дастан)» дип исемләнгән бу китап Казанда 1998 елда дөнья күрде. Соңгы елларда әлеге дастанга, китаби эпос буларак, аерым фольклорчы галимнәр тарафыннан шактый зур фәнни игътибар бирелә килә.

Дастан гаять бай эчтәлекле. Сюжеты бик катлаулы, әлеге мәкаләдә аларның бары тик берсенә – утка табыну йоласы һәм уттан яратылган Иблис образының чагылышына гына тукталырбыз.

Дастанда зур гына ике сюжетны аерып чыгарырга мөмкин: каһарманның җир йөзендә кылган дини-героик маҗаралары хакында сөйли торган өлеш һәм әкияти-мифик дөнья белән бәйле сюжет. Дастан вакыйгалары һәм төп каһарман аша алар бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тора. Эпоста әйтелгән төп фикер – ислам диненең куәтен арттыру, иң төп вакыйга – ислам гаскәренең утка табынучы һиндләрне хак дингә бастыру өчен көрәшүе. Билгеле булганча, милли фольклорның таҗы булган героик эпос соңрак чорда нык үзгәреш кичергән, дини-героик юнәлеш алган, моңа кадәр беркемгә баш имәс кыю батырның холкында Аллаһыга буйсынучанлык сыйфаты чагылыш тапкан. Аллаһыга буйсыну, һәр эшне аңа тапшырып үтәү, Аллаһ кодрәтенә баш ию һәрвакыт дастан вакыйгаларының төп таяну ноктасы булып кала.

«Каһарман Катил» үз эчтәлегенә борынгы Иран пластын да, фарсы мәдәниятының мөселманлык дәверенә нисбәт итәрлек



**Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган дини-героик дастаннар**

традицияләрне дә иркен сыйдырган. Бередә Иран культурасына мөселманлык үтеп кергәнче үк булган күренешләргә юлыгырга мөмкин. «Каһарман Катил»дә дошман патшасының һәм гаскәренең утка табынулары, утка сәҗдә кылулары турында берничә урында телгә алына. Сугыш тынып торган арада һәр ике як үзләренең мәетләрен җыештыра. Ислам гаскәренең вафат сугышчыларына җирләү оештырылса, һиндләр үз мәетләрен утта яндыра.

Утка табынуның һәм мәетне утта яндыруның нигезләре бик борынгы чорлардан, хәтта утка табынучыларның шактый куәтле системаны тәшкил иткән китабы – Авестадан да күп иртә барлыкка килгән булуы мәгълүм. Үлгән кешене яндыру аның җаны югарыдагы зат – Аллаһыга тизрәк күтәрелсен дигән максаттан башкарылган.

Тарихка мөрәҗәгать итсәк, борынгы Иран территориясендә гарәп яулап алуларына кадәр, төгәлрәк әйткәндә VII-VIII гасырларгача, утка табынучылар дине – зәрдөштлек хөкем сөргән. Борынгы Иран диненең изге китаплар җыелмасы «Авеста» дигән исем белән билгеле, ә «зәрдөштлек» төшенчәсе шушы дингә нигез салган легендар пәйгамбәр Зароастр (Заратуштра) исеменнән килеп чыккан. Зәрдөштлек нигезендә ислам дине тәгълиматына капма-каршы булган утка табыну ята. Шуның нәтиҗәсе буларак, мәңгелек ут храмнары зәрдөштлек йолаларында хәлиткеч роль уйный. Үз чорында Иран территориясе тулысынча зәрдөштлек тәэсирендә булган. Авестаның аерым идеяләре Азия һәм Урта диңгез халыкларының дини карашларына, сәнгатенә, әдәбиятына көчле йогынты ясаган.

«Каһарман Катил» дастанында утка табынучыларның үз мәетләрен яндыру гадәте зәрдөштлек традициясе чагылышы булуы ихтимал. Әмма галим Фатих Урманченың «Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлеген»дә (2008) «зәрдөштлектә торучылар мәетне җирләмиләр дә, яндырмыйлар да, кыргый хайваннар һәм кошлар ашап бетер-



**Дини героик дастан «Каһарман Катил».**
**Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондларыннан**

сен дип, ачык килеш ташлап калдыра торган булганнар» дигән мәгълүматына нигезләнсәк, мәетне яндыру гадәтен Авеста дине белән генә бәйләүнең хакыйкатькә туры килеп бетмәве ачыла. Дастанга һинд-иран дин тарихына бәйле реаль вакыйгалар да йогынты ясаган булырга мөмкин. Биредә бер нәрсә төгәл билгеле: мәетне борынгы зәрдөштлектәге кебек җир өстендә калдыру яисә яндыру бик борынгы гадәтләрдән булган, ислам исә моңа чик куйган. Мәетне яндыру гадәтенең тамырлары Авестадан да борынгырак яшәгән традицияләргә үк барып тоташа. Әмма «Каһарман Катил» дастанында бу традицияләргә бәйлелек бик күренми, биредә әлеге йола исламда тыелган гамәл буларак кына килеп кергән.

Дастанда дошман ягының ислам гаскәре тарафыннан үтерелгән сугышчыларын яндырулары турында сүз алып баруны чыннан да исламның өстенлеген ассызыклау, ислам тәртипләренә каршы килә торган күренешне тәнкыйтьләү өчен кулланылган чара дип уйларга нигез бар. Үлгән кешене мөселманча күмү-җирләү тәртипләре дастанда утка табынучы дошманның үз мәетләрен яндыру ритуалына каршы куела. Биредә ислам гаскәренең төп дошманы – утка табынучы һиндләр гаскәре. Утка табынуның да, мәетне яндыруның да тарихи тамырлары безнең эрага кадәрге чорларга ук барып тоташса да, дастанда бу традицияләрнең фәкать риваять характерында һәм фольклор контаминациясе кичергән булуы хак.

«Каһарман Катил»дәге утка табынучыларның Авеста диненә иярүчеләрдән шактый ерагайган булуын, шул сәбәпле күп кенә яклары белән зәрдөштлек традицияләрен ислам күзлегеннән яктыртып, бозып сурәтләвен дастандагы дини-мифик зат Иблис ачык чагылдыра. Авестада Иблис юк. Иблис (яисә шайтан, сатана, дьявол) турында Зәрдөштлек китабында гомумән мәгълүматлар бирелми. Авеста китапларында утка табыну төп урыннарның берсен алып торса да, биредә ут Иблис белән бәйләнештә каралмый. Иблис – тамыры күп төрле чыганакларга барып тоташа торган гаять борынгы чыгышлы үтә катлаулы образ. Кайбер дини тәгълиматларда ул күренекле урын алып тора, ә кайберләрендә, мәсәлән, яһүдләр динендә аның роле бик томанлы.

Иблис – «дьявол»ның исламдагы исеме. Ә «дьявол» – грек сүзеннән – diabolos – сатана, җен, Иблис, кайбер диннәрдә (христиан, ислам һәм башкалар) явыз рух яки явыз рухларның башлыгы, Аллаһы белән каршылыклы мөнәсәбәттә тора, җәһәннәм хакиме, кайбер диннәрдә Аллаһыга каршы торучы явыз рух һәм явыз рухларның башлыгы, тәмуг хуҗасы. Иблис образы төрки халыклар иҗатына һәм язма әдәбиятына шактый тирән үтеп кергән. Әйтик, татар халкының «Күрәзәче карчык» әкиятендә ул – шайтаннар патшасы буларак тасвирланган мөстәкыйль персонаж. Фольклор жанрларыннан мөнәҗәтләрдә дә Иблис образы еш очрый.

Коръәндә Иблис – Аллаһы тәгалә фәрештәләрне, җеннәрне һәм беренче пәйгамбәр Адәм галәйһиссәламне бар иткән вакытта ук яралтылган зат. Аллаһы әмере буенча нурдан яралтылган фәрештәләр дә, уттан яралтылган җеннәр дә Адәм галәйһиссәламгә баш иярге тиеш булалар. Әмма җеннәрдән берсе – Газазил исемлесе Аллаһ әмереннән баш тарта:

– Мин аннан өстенрәк, чөнки мине уттан яралттың, аны балчыктан гына, – ди. («Әгъраф» («Пәрдә» ) сүрәсе, 7:12). «Иблис» сүзе гарәп телендәге «ул өметсез» дигән мәгънәне белдерә торган тамырга

барып тоташа, ягъни Аллаһ рәхмәтеннән чыккан, төзәлергә өмете бөтенләй юк зат дигәнне аңлата. Димәк, Иблис зәрдөштлектән дә күп алда барлыкка килгән булып чыга. Мөселманнарның изге китабында шактый ачык характеристика бирелгән булуга карамастан, Иблисне Коръән персонажы дип тәкърарлау дөреслеккә туры килми, чөнки ул Библиядә дә, аңа кадәр дә шактый телгә алына. Әмма алай да бик иртә барлыкка килгән бу зат турында мәгълүматның татарларга нәкъ менә Коръән аша кергән булуы бәхәссез, биредә Иблис турында шактый тулы аңлатылган: «Кәһаф» («Мәгарә») сүрәсе, 18:48, 18:50; «Хиҗр» («Хиҗр иле») сүрәсе, 15:27; «Рахман» («Рахман») сүрәсе, 55:15.

Идел-Урал буе төркиләреннән татарларда дини эчтәлекле маҗаралы хикәят жанры гаять популяр булган, оригиналь сюжетлы, әмма авторы мәгълүм булмаган мондый әсәрләрдә дә Иблис бик еш тасвирланган. Татарларның әлеге кызыклы һәм гыйбрәтле хикәятләрендә Иблис Коръәндә бирелгән характеристикасына тугрылыкны тулысынча саклый.

«Каһарман Катил» дастанында дошман патшасы һәм гаскәре утка табына. Әмма каршы як, ягъни Һушән шаһның ислам гаскәре күзаллавы буенча, дошманнарның уты артында Иблис утыра, бу зат – аларның аллалары да. Һиндләр, имеш, «олуглап утка сәҗдә итәләр», аларның падишаһлары Раи Һинд утка: «Әй, минем мәгъбүдем *(гыйбадәт кылына торган зат, алла, пот. –* **Л.М.**), нур вә нур – ут!» дип мөрәҗәгать итә, уттан киңәш сорый. Һинд патшасы Раи Һинд уттан Иран падишаһы белән сугышыргамы, әллә килешергәме дип сорап торган бер вакытта «адәмнәрнең һәм диннең дошманы, Җәнабе Хактан сөрелгән Иблис ләгыйн, утның артыннан ачулы тавыш белән» җавап бирә һәм җавабында, әлбәттә, сугышырга өнди, ягъни адәм балаларын котырта. Иблис образында сурәтләнгән Ут-аллаларыннан җиңү вәгъдә ителгәч, һиндләр сугышка күтәрелә һәм шактый тәфсилле сурәтләнгән сугыш-орышлардан соң, ахырда, җиңелә.

«Каһарман Катил»дә утка табынучылар тоткан кыйбланың, Коръәндә тасвирланганча, уттан яралтылган, Аллаһ кушканны үтәмәве аркасында «өметсез» мөһере сугылган Иблис образына ни өчен килеп бәйләнгәнлеге аңлашыла. Утка табынучы кавемгә бәйле вакыйгаларны Иблис арадашлыгында сурәтләү Идел-Урал төркиләренең уттан яралтылган бу зат белән Коръән аша таныш булуларыннан килә. Шуңа күрә, архаик Иран пластына хас Авеста катламы дастанда соңгырак чор күзаллаулар белән керешеп киткән дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Бу – утка табынучыларны тәнкыйтьләгән дастанның нигезен Коръән тәфсирләре белән бәйли торган игътибарга лаек элемент. Тамырлары Коръәннән дә алдарак торган чыганакларга барып тоташуына карамастан, бу эпизод «Каһарман Катил» дастанына Коръән сюжетлары аша кергән дигән нәтиҗәгә киләбез. Бирелә Иблиснең дастандагы дини-мифологик өлештә түгел, ә дөньяви өлештә, ягъни әсәрнең дини-героика белән сугарылган өлешендә тасвирлануы да шуны дәлилли.

Шулай итеп, дастан үзенең сюжетында, образ-персонажларның исемнәрендә, әсәрнең типологик үзенчәлекләрендә фарсы-иран һәм төрки-иран эпик традицияләренә шактый зур тугрылык саклаган. Әмма бирелә дини һәм мифологик мотивлар дастанның Идел-Урал төбәгендә диниидеологик үзгәрешләргә дучар ителгәнлеген дә раслый. Утка табыну йоласын һәм Иблис образын бирүдә җирле мөселманнарның карашлары өстенлек алган. Ислам гаскәре дошманы булган һинд гаскәре сугышчыларының утка табынулары «Каһарман Катил» дастанында Идел-Урал буе татарларына хас дини фәлсәфәгә яраклаштырылган. Бу – дастанның шушында яшәүче халык ихтыяҗларын үтәүгә хезмәт итә торган эпик әсәр булып формалашкан булуыннан килә. Димәк, «Каһарман Катил»дәге дини-мифик образлар, ислам динен тарату яисә ныгыту максаты белән бергә, халык яшәеше кануннарына, җирле үзенчәлекләргә буйсынган. Дастанда чагылыш тапкан дини-мифик йолаларга бәйле мотивларның үзенчәлеге – әлеге йолаларның һичшиксез җирле мөселман карашларына ярашлы үзгәреш кичереп формалашкан булуында.

Автор фоторәсемнәре

*Ләйсән СӘГЫЙРОВА,*
*Питрәч районы мәдәният йорты директоры*

# «БАЛКЫШ» *халык театрының* ТАРИХИ МИЗГЕЛЛӘРЕ



**«Казан егетләре» спектакленнән күренеш**

***Питрәч мәдәният йортының халык театры Шамил Закиров исемендәге XXI «Идел-йорт» төбәкара театр коллективлары конкурсының Гран-при иясе булды – 2021 елның 20 декабрендә коллектив Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры сәхнәсендә М. Гыйләҗевнең «Казан егетләре» спектаклен күрсәтте. Алар үзләренең җиңүләрен якташлары Айдар Хафизовка, «Балкыш»ны Камал театры сәхнәсендә күрергә хыялланган Рифат Баһауовка багышладылар.***

Бүген сезне әлеге коллектив белән якыннанрак таныштырырга телибез.

Үткән гасырның җитмешенче елларында ук район мәдәният йортында үзешчән рус театры эшчәнлек алып бара, питрәчлеләрне үз спектакльләре белән сөендерә. Туксанынчы елларда, рус телле режиссерлар булмаганлыктан, ул татар театрына әверелә. Шулай итеп, 1993 елда Питрәч район мәдәният йортында «Балкыш» театры оештырыла. Аның беренче режиссеры Нәзилә Хәмитова була, ул коллектив белән 2009 елга кадәр җитәкчелек итә. 2008 елда коллективка «Халык театры» исеме бирелә.



Фәнил Мисалов

● 2009-2011 һәм 2014-2016 елларда театрның режиссеры булып яшь һәм талантлы Рифат Баһауов эшли. Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр», Рәдиф Сәгъдинең «Сынган беләзек» һәм Туфан Миңнуллинның «Каяүләр» спектакльләре ул эшләгәндә куела.

● 2011-2013 елларда режиссер Камил Зәйнуллин Туфан Миңнуллинның «Яшьлек белән очрашу» һәм Хәбир Ибраһимның «Вәгъдә» спектакльләрен куя.

Хәзер Нәзилә Хәмитова да, Рифат Баһауов та мәрхүмнәр инде, алар куйган спектакльләр белән бәйле истәлекләр халык күңелендә яши.

● 2016 елда район мәдәният йортына Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтын тәмамлап кайткан Фәнил Мисалов эшкә урнаша. Тумышы белән Әлки районыннан булса да, язмыш аны Питрәч районы белән бәйли. Ул килү белән коллективта яңа тормыш башлана – коллективка яшьләр килә. Репертуар яңартыла, актер осталыгы, сәхнә теле, сәхнә хәрәкәте, вокал, хореография буенча курслар кертелә. Флорид Бүләковның «Әбиләргә ни җитми» пьесасы буенча куелган спектакльне тамашачы яңача күрә. Әлеге спектакль Питрәчтә генә түгел, Саба, Апас районнары тамашачыларына да күрсәтелә.




**«Әбиләргә ни җитми» спектакленнән күренеш**



**Драматург Мансур Гыйләҗев «Балкыш» халык театры колективы белән**



**«Үз хатыныма өйләнәм» спектакленнән күренеш**

2020 елда коллектив Мансур Гыйләҗевнең «Казан егетләре» пьесасын куярга алына. Ел ахырында спектакль тамашачыга күрсәтер өчен әзер була. Туксанынчы елларда Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры куйган легендар спектакльне Питрәч тамашачылары түземсезлек белән көтә. Спектакльнең премьерасы 2021 елның гыйнварына билгеләнә. Кемдер спектакльне Камал театрындагы куелышы белән чагыштырырга, кемдер хәтердә яңартырга дип килә, аны хәтта беренче тапкыр күрүчеләр дә була.

Камал театрының легендар спектаклен халык театрында кую җиңел эш түгел, әлбәттә. Артистлар аны башкарып чыга алмаудан курка, тамашачы бу спектакльне кабул итмәс дип шикләнәләр, режиссер да борчыла. Аның башында бер уй гына була: «Яшьләр уйнаган спектакльне тамашачы ничек бәяләр? Пьеса авторы Мансур Гыйләҗев үзе ни дияр? Раушания Юкачева спектакльне кабул итәрме?» Чөнки спектакль премьерасына алар да чакырылган була.

Ниһаять, спектакльнең финал җыры яңгырый – зал алкышларга күмелә. Әле генә килгән тамашачы сәгать ярым вакыт узганын сизми дә кала. Драматург сәхнәгә күтәрелеп, аның пьесасын кабат искә төшерүләре өчен театр коллективына рәхмәт белдерә. Раушания Юкачева районда театр сәнгатен популярлаштырган һәм, әлбәттә, нәкъ менә шушы спектакльне куйганнары өчен артистларга рәхмәт белдерә.

2021 елда «Балкыш» халык театры тагын бер спектакль куя. Режиссер, артистлар белән киңәшеп, йөзләгән пьесаларны укып, Наил Гаетбайның «Үз хатыныма өйләнәм» пьесасына туктала. Беренче карашка җиңел комедия булып тоелган пьеса, репетицияләр башлангач, шактый кыенлыклар тудыра. «Аңлагыз, тормышны уйнау авыр», – ди артистларның берсе Илнур Хәлимов. «Уртак карар кабул итәргә кирәк – йә уйныйбыз, йә юк, йә куябыз, йә юк», – ди Фәнил репетициядә. 15 минут тынлык: артистларның кайсылары дәшми, кемдер елый. Ахыр чиктә спектакль куела. Аның премьерасы 2021 елның ноябрендә – «Театр атналыгы» район марафонының соңгы көнендә уза. Тамашачы һәр актерда үзен күрә.



**Спектакльдан соң**

Спектакль тәмамлангач, зал алкышларга күмелә: кемдер елмая, кемдер күз яшьләрен сөртә. Шул көнне тамашачы булып залда утырган Салават Фәтхетдинов сәхнәгә менеп, үзенең хис-тойгылары, кичерешләре белән уртаклаша. Спектакльнең премьерасында Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакиров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла һәм башка бик күп мәртәбәле кунаклар да була.

● Питрәч районында «Театр атналыгы» район марафоны 2019 елдан бирле үткәрелә, аның максаты – районда театр сәнгатен үстерү, атна дәвамында район мәдәният йорты сәхнәсендә үзешчән коллективларны күрсәтү. 2021 елдан марафон Питрәч районы Күн авылында туып-үскән, Россиянең атказанган артисты, Татарстанның халык артисты Айдар Хафизов истәлегенә багышлана.

«Балкыш» театр коллективы – тере, үзгәрүчән, хәрәкәтчән организм. Теләсә кайсы тере җан кебек, ул үсә, авырый һәм савыга, җиңелә һәм җиңә. Театрда катнашучылар Питрәч районы башлыгының, Бөтендөнья татар конгрессының, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә. Театр конкурс һәм фестивальләрдә катнашып, дипломнарга ия була, ул «Театр дөньясы» Халыкара театр сәнгате конкурсының 1 дәрәҗә лауреаты.

Театрның уңышы костюмер, декоратор, рәссам-бизәүче, куелыш бүлеге мөдире һәм башкаларның беренче карашка күренми һәм сизелми торган хезмәтләреннән башка да мөмкин түгел. Уртак иҗат кичәләрне магнит кебек җәлеп итә, шуңа күрә алар бердәм коллектив булып эшли.

● 2022 елга театр үзенең гастроль эшчәнлеген дә планлаштыра, бик тиздән районның торак пунктларында һәм республика районнарында яшәүчеләр аның спектакльләрен карый алачак.

Питрәч районы дөньяга Айдар Хафизов, Раушания Юкачева, Фердинант Хафиз, Камил Кәримов, Ренат Әюпов, Луиза Янсуар, Зөфәр Хәйретдинов, Ренат Шәмсетдинов, Илнур Нуриев һәм башка танылган язучылар, драматурглар, артистлар бүләк иткән. Кем белә, бәлки, киләчәктә әлеге шәхесләр арасында «Балкыш» халык театры артистлары да булыр.

Фоторәсемнәр «Балкыш» халык театры архивыннан

*Әсгать МӨХӘММӘТҖАНОВ,*
*Казан, 167 нче мәктәпнең югары категорияле физик тәрбия укытучысы*

# МИЛЛИ МӘДӘНИЯТКӘ – *милли уеннар аша*



***Татар халкының мәдәни мирасы бик бай. Яшь буында рухи-әхлакый кыйммәтләр формалаштыруда халык ядкәрләре зур роль уйный. Татар халкының әхлакый-тәрбияви карашларының мөһим чыганагы – халыкның тормыш-көнкүрешен, традицияләрен һәм гореф-гадәтен чагылдыра торган халык иҗаты. Милли мәгарифнең асылы дөнья мәдәнияте җәүһәрләрен гасырлардан килгән халык йолалары белән баетуда ачыла. Мәгариф бу очракта төрле буыннарны һәм халыкларны тоташтыра торган үзенчәлекле күпер ролен үти. Халык тәрбиясе традицияләре потенциалын җентекләп педагогик процесста кулланганда милли мәгарифнең киләчәге өметле дип әйтә алабыз.***



### УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСКӘНДӘ...

Яшь буынның рухи яктан бай, физик яктан сәламәт булып үсүендә, мәсәлән, милли уеннарның әһәмияте әйтеп бетергесез. Уеннарның яшь буынны физик һәм әхлакый тәрбияләү, киләчәк тормышка әзерләү функциясен үтәве галимнәр тарафыннан инде расланган. Фольклористикада галимнәребез уеннар темасына еш мөрәҗәгать иткәннәр, классификацияләгәннәр, педагогикада файдаланганнар. Әйтик, М. Иванов, С. Кукляшев, К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Толымбайский, Н. Исәнбәт, Р. Ягъфәров кебек күренекле затлар татар халык иҗатының әлеге жанрына игътибар биргән. Алар – балалар уеннарын халыктан туплаган һәм бу төр иҗатны төрле яклап өйрәнеп, китапларга теркәгән шәхесләр.



Бүгенге фән-техника заманында татар халкының гореф-гадәтенә туры килә торган уеннарның функциясе чикләнә баруны күзәтәбез. Кайчандыр гаять актуаль шөгыль саналган күп кенә кызыклы милли уеннар онытыла төшкән. Бүгенге буын балаларының уенга булган ихтыяҗларын югары технологияләргә исәпләнгән заманча мавыгулар канәгатьләндерә. Әмма миллилекне саклау, үз йөзебезне югалтмау өчен һәм яшь буынны традицион мәдәният белән таныштыру максатыннан бүгенге көндә татар милли уеннарына игътибар бирү аеруча мөһим. Татар баласында милли үзаң, милли рух тәрбияләү, башка милләт балаларын татар милли мохитенә тарту, аларда милли мәдәнияткә карата кызыксыну уяту максатыннан татар халык уеннарын мәктәптә – физик тәрбия дәресләрендә кулланырга тәкъдим итәбез.

## УЕННАР ТӨРЛЕ БУЛА

Уенны әби-бабаларыбыз кечкенә чакта уйнаганча түгел, нәкъ менә бүгенге яшьләргә-балаларга кызыклы булырлык итеп, хәтта заманча технологияләрне дә эшкә җигеп, тәкъдим итү мөһим. Физик тәрбия дәресләренә этник элементларны кертеп җибәрү коллективтагы эмоциональ фонга да уңай тәэсир итә.

Хәрәкәтле уеннар бик күп төрле һәм алар берничә принциптан чыгып төркемләнә. Мәсәлән, түбәндәге төрләрне аерып күрсәтә алабыз: уенчылар командаларга бүленә һәм бүленми торган төр; төп хәрәкәтләрнең тибы буенча – йөгерү, сикерү, үрмәләү, ыргыту күнекмәләрен үз эченә алган төрләр; килеп чыгышы ягыннан – халык уеннары, коллектив һәм индивидуаль уеннар. Балалар уенын фольклор үрнәге буларак караганда, уеннарны композицион үзенчәлеге (структурасы) буенча төркемләү кабул ителгән. Болардан тыш, балалар өчен уеннарны сюжетлы һәм сюжетсыз хәрәкәтле уеннар дигән ике төркемдә карарга мөмкин.

Татар фольклорында, мәсәлән, уеннарның иң зур төркемен хәрәкәтле уеннар тәшкил иткәнлеге мәгълүм. Аларның нигезендә йөгерү, сикерү, үрмәләү, атлау, ыргыту һәм башка хәрәкәтләр ясау ята. Физик тәрбия дәресләре программасы да халык уеннары составындагы әлеге күнекмәләр белән җиңел ярашканга, дәресләргә мондый уеннарны рәхәтләнеп кертеп җибәрергә була.

Сюжетлы хәрәкәтле уеннарга рольләргә бүленешеп уйнау хас. Бу үзенчәлекне исәпкә алып, татар балалар фольклорында мондый уеннарны «драма уеннары» дип йөртәләр. Рольләрне башкаручылар уен кагыйдәсе чикләреннән чыкмый. Шунлыктан аларның ни эшләячәге баштан ук билгеле була.

## АЛЫРМЫН КОШ

Мәсәлән, *«Алырмын кош»* уены тулы бер спектакльне хәтерләтә. Монда һәр уйнаучыга роль бирелә: ана каз, козгын, бәбкәләр. Уен бер урында, бер вакытта бара. Ягъни театрга хас урын һәм вакыт берлеге



кануны мондый уеннарда да күзәтелә. Театраль күренеш барган урын, әйтик, – спорт залы. Сюжет тәенләнештән башлана: ана каз үзенең бәбкәләрен зал уртасына алып чыга, бәбкә ролендәгеләр үлән ашау, су эчү хәрәкәтенә охшаш хәрәкәтләр ясый. Вакыйга үсеше бәбкәләр янына козгын килеп чыгу, аның бәбкәләр тирәли йөрүе аша ачыла. Конфликт козгынның бәбкәләрне тартып алуы, ана казның аларны саклап калырга тырышуы белән бәйле. Биредә һәр уенчыдан өлгерлек, җитезлек, осталык таләп ителә.

Уенда козгын ана казның игътибарын бәбкәләрдән башка нәрсәгә юнәлтә торган хәйләле сүзләр әйтә. Элек «Әнә, күктән койрыклы йолдыз төшә!» кебек гыйбарәләр белән игътибар читкә юнәлтелсә, хәзер физик тәрбия темасына сораулар тәкъдим итәргә мөмкин. Бәбкәләрен саклау барышында козгын тарафыннан түбәндәге сораулар бирелә ала: «2013 елның җәендә Казанда нинди зур спорт ярышы үтте?»; «Нинди бөек татар спортчыларын беләсез?»; «Футбол командасында ничә кеше катнаша?»; «Олимпия уеннары символындагы үзара тоташкан биш бөҗра нәрсәне аңлата?»; «Кайсы туп авыррак: баскетболныкымы, әллә волейболныкымы?»; «Нинди милли спорт төрләрен беләсез?» һәм башкалар.

Бу һәм башка милли уеннарны дәрес элементы итеп планлаштырганда, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, физик культура һәм спорт темасына баш-

ка сораулар да әзерләргә мөмкин. Әйтик, *«Алырмын кош», «Кем кирәк?», «Буяу сатам»* уеннарында алып баручы, сораулар белән аптырата-аптырата, уенчыларны «чүпләвен» дәвам итә. Шуңа күрә уенда катнашучылар, сорауларга дөрес итеп җавап бирү белән бергә, «эләктерүче» тырнагына эләкмәс өчен бик уяу булырга тиешләр.

### КЕМ УЛ ХАН?

*«Хан»* уенында да күп кеше берьюлы катнаша ала. Уйнаучылар арасыннан берсен хан итеп сайлап куялар. Үзләре читкә китеп берәр эш турында уйлап, хан янына киләләр.

– Исәнмесез, хан хәзрәтләре! – диләр.

Хан боларга:

– Исәнмесез! Кайда йөрдегез? Ниләр күрдегез? Сөйләп бирегез! – ди.

Шуннан балалар алдан уйлаган эшләрен кул хәрәкәтләре белән күрсәтеп аңлата башлыйлар. Бу хәрәкәтләрдән хан берни аңламаса, уен кабат шул ук рольдә дәвам итә. Хан эшне аңлап алып, ни турында сөйләүләрен әйтеп бирә алса, уенчылар төрлесе төрле якка таралыша, йөгереп качалар. Хан арадан берсен тотып калырга тиеш. Тотылган бала хан була, уен шул ук тәртиптә дәвам итә.

Бүгенге шартларда бу уенны бераз үзгәртеп уйный алабыз. Әйтик, ханның соравына җавап итеп, төрле спорт төрләрендәге хәрәкәтләр күрсәтелә. Мисал өчен, балалар чаңгы шуудагы «бер адымлы шуу» («одношажный ход» ), «ике адымлы шуу» (двухшажный ход» ), «адымсыз йөрү» («бесшажный ход» ) яисә чаңгыда таудан менгәндәге «чыршы ясау» («ёлочка» ) алымнарын хәрәкәтләр белән аңлата. Баскетбол тубын дөрес итеп кәрҗингә кертү ысулын, тупны идәндә йөртү кагыйдәсен, волейбол тубын каршы як командага бирү («подача волейбольного мяча» ) кебек кагыйдәләрне дә туп кулланмый гына сүзсез хәрәкәт белән күрсәтәләр. «Хан» уены темага кагылышлы белемнәрне ныгытырга, спорт төрләрен тагын да популярлаштырырга ярдәм итә, эмоциональлекне, дөрес хәрәкәтләр ясый белүне үстерә. Уен алдыннан татар халкында әлеге исемдәге милли уенның булуы, аның дәүләтчелек белән бәйле тарихы, «хан» титулының нәрсә аңлатуын күрсәтеп үтү физик тәрбия дәресләренең дисциплинаара принципларын да ныгытырга ярдәм итә.

Үзләрен нинди дә булса образда күзаллау уйнаучыларны рольгә кертә, иҗат мөм-



кинлекләрен ача. Физик тәрбия дәресләрендә йөгерү, сикерү, чаңгыда узышу, йөзү кебек күнекмәләрне сюжетлы хәрәкәтле уеннарга нигезләп башкару уенга тизрәк кереп китәргә, тиешле күнекмәләрне җиңел үзләштерергә булыша.

### АЛМАЧУАР АТЫМ БАР...

Сюжетсыз милли уеннар исә гел хәрәкәттән генә тора. Нинди дә булса конфликтка корылган сюжет мондый уеннарда күзәтелми, роль бүлешү дә юк, әмма һәркайсының үз кагыйдәсе бар. *«Өченче кеше артык», «Дүртпочмак», «Ун таяклы», «Унике таяк», «Әбәкле», «Очты-очты», «Аша-ашама»* кебек уеннар шундыйлар рәтенә керә. Сюжетыз хәрәкәтле уеннарның кайберсендә качып котылу, икенчеләрендә узышып көч сынашу, өченчеләрендә утырырга ирек бирмичә, бастырып тоту максат итеп куела. Мондый уеннар командаларга бүленеп уйнала. Әйтик, качыш уеннары, гадәттә гөрләүче, ягъни котүче сайлаудан башлана. Менә, мәсәлән, «Ун таяклы» дип аталган уенда көтүчене болай сайлыйлар:

*Әлчи, бәлчи,*
*Әни күлмәк үлчи.*
*Әнә тора чыпчык,*
*Син кал, бу – чык.*

Яисә:
*Алмачуар атым бар,*
*Мактанырга хакым бар,*
*Бер көн атым чыгып киткән,*
*Йөгереп барып тотып алдым,*
*Бу уенда син калдың.*

Сюжетсыз хәрәкәтле уеннар тән сыгылмалылыгын арттыру, кыюлык, җитезлек кебек сыйфатлар тәрбияләү ягыннан әһәмиятле. Физик тәрбия дәресләрендә аларны куллану мөмкинлеге сюжетлы милли уеннарга караганда да күбрәк, уен тәртибенең гадилеге, елгырлыкны сынауга корылганлыгы бу төр милли уеннарга карата да балаларның игътибарын тиз җәлеп итә ала.

Хәрәкәтле милли уеннарның сюжетлылары да, сюжеты булмаган төре дә



кешедә кыюлык, чыдамлык, ихтыяр көче һәм башка әхлакый сыйфатлар тәрбияли. Уендагы активлык, уен һәм аның нәтиҗәсе белән бәйле шатлыклы кичерешләр кәефне күтәрә. Уен кагыйдәләре җиңүне гадел көрәштә яуларга өйрәтә, җитезлекне генә түгел, зирәклекне дә сыный. Уеннар аша бала дөньяны танып белә, матурлыкны күрергә өйрәнә. Уеннар уй-фикерне зыянлы гамәлләрдән читкә юнәлтә, юньле эшләр кылу юнәлешен алга сөрә.

Милли уеннар физик мөмкинлекләрне арттырып кына калмый, аң-зиһенне үстерүгә дә булыша, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне актуальләштерә, балаларны татарларның рухи хәзинәсе белән таныштыра. Яңартып кулланганда милли уеннар әле дә зур тәрбия чарасы булып тора. Халык уеннарын барлап, аларның физик тәрбия дәресләрендә кулланырдайларын сайлап алу, максатка ярашлы рәвештә аларны гамәлгә кертү шуны раслый. Яшь буында шушы рәвешле милли хисләр тәрбияләнүе милли мәгарифнең генә түгел, милли мәдәниятебезнең дә аерылгысыз өлешен тәшкил итә.

**Чыганаклар:**
Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз уен // Төзүчесе, фәнни мәкаләләр һәм искәрмәләр авторы Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 275 б.
Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры // Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Ягъфәров Р.Ф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 336 б.

Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивы һәм автор фоторәсемнәре

# «Uen Fest-Уен Фест»: *иҗади смена*





***Яшел Үзән районының Әйшә бистәсе янәшәсендә урнашкан «Мирас-Наследие» лагере февраль азагында «Uen Fest-Уен Фест» традицион уеннар фестивалендә катнашучыларны иҗади сменага җыйды.***

Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге оештырган сменага «Дәррәү-Derrey» этномузыка лабораториясендә катнашучы фольклор коллективлары һәм халык уены төшерелгән иң яхшы





видеоролик бәйгесендә җиңүчеләр чакырылды. Лагерьга Түбән Кама, Саба, Тукай, Нурлат һәм Буа районнарыннан иллеләп бала җыелды.

Катнашучылар чүлмәк ясау, тукымадан курчак тегү буенча осталык дәресләрендә катнаштылар, халык уеннары өйрәнделәр. Программада тамашачы алдында чыгыш ясау осталыгы буенча да дәресләр каралган иде.

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

**Казан шәһәре, 11 нче татар гимназиясенең**
**1 нче «Б» сыйныфы укучылары иҗаты (укытучылары – Наҗия Нәҗипова)**



**«Карга боткасы». Ралинә НАСЫЙРОВА рәсеме**

*Әлфия СИТДЫЙКОВА*

## Карга боткасы

«Карга боткасына йөрдек
Сезнең кебек чакта», – ди.
Хатирәләрен яңартып
Сөйләгәндә дәү әни.

Аңлый алмыйбыз сүзеңне
Дәү әнием нигәдер.
Ботка пешергән карганы
Әле бер дә күрмәдек.

Дәү әни көлә кеткелдәп:
«Без пешердек ботканы.
Каргаларга бирә идек
Үзебездән калганны.

Кырда пешкән ботка тәме
Һаман да дип авызда»,
Карга боткасына безне
Алып кайтты авылга.

## Нәүрүз килә!

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә!
Кояш җылы нурын сибә.
Нәүрүз – язның ачкычы,
Гөл, чәчәкле баскычы.

**Адель ВАФИН**

## Яшик изге теләктә

Ап-ак тунлы кыш үтте,
«Нәүрүз»  килеп җитте.
Яз шатлыгы йөрәктә,
Яшик изге теләктә.

**Зәмирә ЛОТФУЛЛИНА**

# Җир йокысы

Габдулла Тукай сүзләре

Наилә Яхина музыкасы




*Кырга ак кардан*
*Юрган ябылган;*
*Җир язга чаклы*
*Уйкуга талган.*

***Кушымта:***
*Ул тормас, йоклар.*
*Кышлар үтмичә, –*
*Кыйбладан кошлар*
*Кайтып җитмичә.*

*Язның айлары.*
*Апрель, майлары.*
*Бик матур сызлып*
*Аткан таңнары.*

***Кушымта.***

*Урман шаулавы,*
*Кошлар сайравы.*
*Күкләр күкрәве,*
*Яңгыр аннары.*

***Кушымта.***

*Коену көн саен*
*Кояш нурында;*
*Аннан соң тагын*
*Төшкән чык төндә.*

***Кушымта.***

*Бу хәлләр җиргә*
*Барчасы бергә*
*Калган тик инде*
*Төштә күрергә.*

***Кушымта.***

*Җир йоклый тыныч,*
*Күреп тәмле төш.*
*Уяныр әле,*
*Тукта, үтсен кыш!*

***Кушымта.***

# Милли аш-суның барлыкка килү тарихыннан

Татар халкы аш-су төрләренең барлыкка килүенең күп гасырлык тарихы бар. Ул безнең көннәргә кадәр гореф-гадәтләребезне саклап калган. Аш-су төрләренең кабатланмас үзгә булуына сәяси шартлар һәм географик киңлекләр сәбәпче, чөнки аны – урманлы төньяк һәм далалы көньяк чикләп алган. Шулай ук Чулман белән Идел елгасының да йогынтысы зур булган. Бу янәшәлек сәүдә һәм азык-төлек алмашы үсешенә китергән. Халык куллана торган азык тагы да төрләнгән: татар көнкүрешенә дөге, чәй, киптерелгән җиләк-җимеш, чикләвек, төрле тәмләткечләр үтеп кергән.  Әмма татар аш-суында төп урынны бөртекле культуралар һәм терлек ите алып тора. Утрак тормыш алып барган һәр татарның үз хуҗалыгында җитештерелгән бөртекле культуралардан һәм үзе асраган мал-туардан ризык әзерләве бер дә гаҗәп түгел. XIX гасыр ахыры XX гасыр башында халыкта бәрәңге куллану арта. Әмма бакчачылык белән шөгыльләнү җир эшкәртү, иген игүгә караганда күпкә калыша. Яшелчәләрдән, нигездә, суган, кишер, шалкан, кабак, әче торма, чөгендер үстерелә, кәбестә, кыяр аз утыртыла. Бакчалар күбрәк Иделнең уң як ярында урнашкан була. Анда алманың җирле сортлары, чия, карлыган, кура җиләге үсә. Җирле халык урман җиләкләрен, чикләвек, колмак, балтырган, кузгалак, бөтнек, кыргый суган җыя. Гөмбә милли аш-суда артык кулланылмый. Ул бары соңгы елларда, аеруча шәһәр халкы арасында, популярлаша башлады. Татарлар арасында умартачылык та бик борынгы һәм киң таралган шөгыль. Бал (соңрак рамлы умарталар балы) һәм балавыз һәрвакыт кулланышта була.

Идел буе татарлары борынгыдан игенчелек белән терлекчелекне бергә алып барган. Мөгезле эре һәм вак терлек асраган. Җир эшкәртү һәм җигү өчен атлар тотканнар. Ат итеннән аш-су әзерләнсә дә, атлар ит өчен махсус үрчетелмәгән. Идел буе татарларында сарык ите шактый киң кулланылган, әмма казах, үзбәк халкы аш-суындагы кебек өстенлек итмәгән. Сарык ите белән беррәттән сыер ите ашалган. Хуҗалыкта сыер асралып, эремчек, каймак, катык, әйрән кебек сөт ризыклары әзерләнгән. Йомырка һәм ит өчен татар халкы каз, тавык, үрдәк асраган.

Бүгенге көндә татарның милли ризыклары бик яратып әзерләнә. Алар бәйрәм табынының гына түгел, көндәлек өстәлнең дә бизәге булып тора. Халкыбызның аш-су традицияләре һәр гаиләдә саклана.

2021 елның декабрендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге белән берлектә «Татарханә» проектын гамәлгә ашыра башлады.

«Татарханә» – «Татар киеме», «Татар табыны» рубрикаларында татар халкының этномәдәни мирасын тәкъдим итүче тарихи-агарту онлайн проекты.

«Татар табыны» рубрикасында белгечләр милли кухняның затлы ризыклары һәм чәй табыны үзенчәлекләре турында сөйләделәр, «Килен токмачы», «Кияү пилмәне», «Каклаган каз» әзерләү буенча мастер-класслар уздырдылар.

«Тәмле булсын» ресторannар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы Резидә Кыям кызы Хөсәенова бәлеш, гөбәдия, чәк-чәк, өчпочмак, кыстыбый, шәңгә кебек ризыкларны пешерергә өйрәтте, аш-су серләре белән уртаклашты, Татарстанның атказанган артисты Динә Латыйпова татар халкының гореф-гадәтләре, ризыкларның исем тарихлары белән таныштырды.



БҮГЕН РЕЗИДӘ ХАНЫМ СЕЗНЕ ТУЙЛАРНЫҢ КҮРКЕ БУЛГАН, БИК ТИЗ ҺӘМ ҖИҢЕЛ ӘЗЕРЛӘНӘ ТОРГАН КОШ ТЕЛЕ ПЕШЕРЕРГӘ ӨЙРӘТӘ.

# КОШ *теле*



КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**5 данә йомырка,**
**0,5 чәй кашыгы шикәр комы,**
**0,5 чәй кашыгы тоз,**
**токмач камыры килеп чыгарлык он.**



**1**

2 йомырканы агын да, сарысын да кушып сытабыз, 3 йомырканың сарысын гына алабыз. Аңа тоз, шикәр комы салып, яхшы итеп күпертәбез.



**2**

Өстенә он салып, камыр басабыз. Аны пленка астында 10-15 минут ял иттерәбез.



**3**

Камыр ял иткән арада сыек майны кыздыра торабыз.



**4**

Камырны, токмач камырыдай җәеп (бик нәзек ярамый!), махсус кискеч белән ромбиклап кисәбез.



**5**

Кызган майга бер телем ромбикны салып, кайнарлыгын тикшерәбез. Кош теле күпереп чыкса, башка кисәкләрен дә салып болгатабыз, алтынсу төсенә кергә алып, мае аксын өчен дуршлагка җыя барабыз.



**6**

Әзер кош телен матур вазага тезеп, өстен кызыл гөлбәнәкләр белән бизәп, шикәр комы сибеп, кунаклар алдына чыгарабыз.

***Ашларыгыз тәмле булсын!***

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Шахворд

Нәүрүз – төрки халыкларның кышны озату, язны каршылау бәйрәме.

Хөрмәтле укучылар! Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән шахмат фигурасы – атның дөрес йөреш тәртибен кулланып, нәүрүз бәйрәменә багышланган шигырь куплетын укыгыз.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ! | л | с | о | ә | е | з | ы | р |
| а | м | Т | Н | д | е | р | ү | с | ? |
| л | а | р | и | е | з | | | ү | г |
| р | н | ә | | | л | б | ? | Н | е |
| ж | е | к | ч | е |  | | | ы | з |
| е | ә | с | | | | | и | з | ә |
| б | у | | | ә | | | | ж | з |
| л | ө | | | | | р | | ү | г |
| х | , | и | ч | о | т | , | ү | , | и |
| с | е | р | е | Н | з | т | т | ә | р |

Шахвордның җавабы – саннарда

Бер сан бер хәрефкә туры килә. Шигъри юллар 78 хәрефтән тора.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 19 | 16 | 37 | 2 | 21 | 56 | 39 | 4 | 23 |
| 17 | 36 | 1 | 20 | 55 | 38 | 3 | 22 | 57 | 40 |
| 34 | 15 | 18 | 53 | 70 | 77 | | | 24 | 5 |
| 51 | 68 | 35 | | | 54 | 71 | 78 | 41 | 58 |
| 14 | 33 | 52 | 69 | 76 |  | | | 6 | 25 |
| 67 | 50 | 75 | | | | | 72 | 59 | 42 |
| 32 | 13 | | | 74 | | | | 26 | 7 |
| 49 | 66 | | | | | 73 | | 43 | 60 |
| 12 | 31 | 64 | 47 | 10 | 29 | 62 | 45 | 8 | 27 |
| 65 | 48 | 11 | 30 | 63 | 46 | 9 | 28 | 61 | 44 |

**Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем фәннәре академиясе академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде**

**Шахвордның җавабы:**

Торыгыз, тор хуҗалар!
Нәүрүз житте, беләмсез?
Нәүрүзчеләр килде сезгә,
Ни сөенче бирәсез?

# Истәлекле даталар
# 2022

## АПРЕЛЬ

**2 апрель**
Шагыйрь Ләис Мәүлит улы Зөлкарнәйгә (Харрасовка) 60 яшь (1962)

**10 апрель**
График, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Риат Заһретдин улы Мөхәметдиновка 70 яшь (1952)

**14 апрель**
Архитектор, 1971-1990 елларда Казанның баш архитекторы булган Мөнир Хәсән улы Агишевның тууына 90 ел (1932-1994)

**20 апрель**
Шагыйрә Сания Юныс кызы Әхмәтҗановага 60 яшь (1962)

**25 апрель**
Театр-декорацияләр сәнгате рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык рәссамы Сергей Геннадьевич Скомороховка 70 яшь (1952)

## МАЙ

**10 май**
Режиссёр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Чаллы курчак театрының баш режиссёры Александр Моисеевич Янкелевичка 75 яшь (1947)

**15 май**
Гобойчы, педагог, ТАССРның атказанган артисты Мөбәрәк Вазыйх улы Батталовның тууына 110 ел (1912-2006)

**15 май**
Актёр, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты Нәҗип Сәмигулла улы Гайнуллинның тууына 110 ел (1912-1969)

**21 май**
Актёр, режиссёр, педагог, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының баш режиссёры, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәрит Рәфкать улы Бикчәнтәевкә 60 яшь (1962)

**22 май**
Дәүләт эшлеклесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинга 75 яшь (1947)

**25 май**
Рәссам, табигать күренешләрен тасвирлау жанры остасы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Рауль Вәли улы Нурмөхәммәтовның тууына 100 ел (1922-1988)

**30 май**
Җырчы, ТАССРның халык артисты Әлфия Әхмәт (Әхәт) кызы Галимованың тууына 90 ел (1922-2015)

## ИЮНЬ

**1 июнь**
Рәссам Зиннур Миннәхмәт улы Миннәхмәтовка 75 яшь (1947)

**2 июнь**
Актриса, Татарстанның атказанган артисты Фирая Барый кызы Әкбәровага 70 яшь (1952)

**3 июнь**
Актриса, Татарстанның халык артисты Гөлүсә Гомәр кызы Җамалиева (Гайнетдинова)га 70 яшь (1952)

**4 июнь**
Шагыйрә, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Эльмира Мөхәммәт кызы Шәрифуллинага 75 яшь (1947)

**6 июнь**
Актриса, Татарстанның атказанган артисты Әлфия Якуп кызы Хәсәновага 70 яшь (1952)


**18 июнь**
График, архитектор, ТАССРның һәм Россия Федерациясенең атказанган архитекторы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Герман Алексеевич Бакулинга 75 яшь (1947)

**19–21 июнь**
30 ел элек I Бөтендөнья татар конгрессы булды (1992)


**20 июнь**
Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Вильсун Минниян улы Хәкимовка 75 яшь (1947)

https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды









**Кадерле укучыларыбыз!**
2022 елның икенче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 192 сум 67 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 385 сум 34 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!